وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№11 (232). Ноябрь – 2014 / Мөхәррәм – 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





2 бит

## АНТАРКТИДАДА БЕРЕНЧЕ АЗАН ЯҢГЫРАЯЧАК



4-5 бит

## "МӨНБӘР"НЕҢ БУ СӘХИФӘСЕ АХИРӘТКӘ ИЛТӘ ТОРГАН ЮЛ ТУРЫНДА



8 бит

## АНДА БАРМАУ МӨМКИН ТҮГЕЛ...




12 бит

## НӘРСӘ УЛ ХӘЛӘЛ? "АЗАН" РАДИОСЫНДА ШУЛ ХАКТА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

## ТАТАРСТАН МӨФТИЕ БМО УТЫРЫШЫНДА КАТНАШТЫ

***Женевада Берләшкән Милләтләр Оешмасы дини һәм аз санлы милләтләр мәсьәләләре буенча форумының җиденче сессиясе узды. Аның утырышында Россия делегациясе составында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.***

Утырышта сүз аз санлы милләтләрне һәм диннәрне саклау мәсьәләләре турында барды. Шулай ук милләтләргә һәм диннәргә карата көч куллану, аларның хокукларын кысу очракларын туктатып калу ысуллары тикшерелде.

Белүебезчә, Камил хәзрәт РФ Чит илләр эшләре министрлыгы делегациясе белән БМО оешмасы тарафыннан уздырыла торган рәсми чараларда өченче мәртәбә катнаша. Сентябрь аенда Женевада чит ил дипломатлары Татарстан һәм республикабызда алып барылган дини эшчәнлек белән танышканнар иде. Мөфти һәм нәзарәт вәкилләре "Ислам - тынычлык дине" дигән темага түгәрәк өстәлдә катнашып, ТР МДН алып барган юнәлешләрне тәкъдим иттеләр.

## ДИНИ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ ВӘКИЛЛӘРЕ КАЗАНГА ҖЫЕЛДЫ

***Республиканың төрле төбәкләреннән Казанга дин темасын яктыртучы журналистлар һәм дини оешмаларның мәгълүмати чаралары вәкилләре, югары уку йортларының журналистика факультетлары галимнәре җыелды. 26 ноябрьдән 1 декабрьгә кадәр Казанда ТР МДН, РИУ һәм КФУ тарафыннан "Дини белемне үстерү буенча мөселман лидеры мәктәбе", "Мөселман оешмаларының медиасәясәте һәм мәгълүмати стратегияләре" курслары һәм шушы ук темага багышланган түгәрәк өстәл уздырыла.***

Әлеге чаралар кысаларында дини оешмаларның мәгълүмати эшчәнлеге, ораторлык осталыгы, мөселман журналистикасы, интернет үзенчәлекләре, мөселман журналисты этикасы һәм башка темаларга лекцияләр укыла. Казан, Мәскәү, Түбән Новгород, Махачкала шәһәрләре белгечләре чыгыш ясый.

*Түгәрәк өстәл 29 ноябрьдә КФУ бинасында (Татарстан урамы, 2) узачак.*

## КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ ISLAM.RU ДА БЛОГЫ БАРЛЫККА КИЛДЕ

***Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин www.islam.ru сайтында үзенең блогын ачты.***

Биредә мөфти хәзрәт дини темаларга мәкаләләр язып, дингә кагылышлы мәсьәләләре буенча фикерләре белән уртаклашыр дип көтелә.**http://www.islam.ru/content/kolonka_avtora/12442** сылтамасы буенча кереп, хәзрәтнең "Аллаһы Тәгаләнең өч үзгәрешсез кагыйдәсе" исемле беренче мәкаләсе белән танышырга мөмкин. Моннан тыш Камил хәзрәт Сәмигуллин islam-today.ru сайтында да блог алып бара.

# ДИНИ ҺӘМ ДӨНЬЯВИ УКУ ЙОРТЛАРЫ АРАСЫНДА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮ ТУРЫНДАГЫ КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ



***Казан (Идел буе) федераль университетында дүрт яклы килешүгә кул куелды. Казан рухи семинариясе, Россия ислам институты, Россия Фәннәр академиясенең Шәрыкне өйрәнү институты һәм Казан федераль университеты уртак фәнни тикшеренүләр уздырырга, фәннимәгърифәтчел, мәдәни, мәгълүмати чаралар оештырырга һәм нәшрият өлкәсендә хезмәттәшлеккә үстерергә килештеләр. Килешүгә дини һәм дөньяви уку йортлары җитәкчеләре кул куйды.***

Әлеге рәсми чарада күп сандагы дин вәкилләре һәм галимнәр катнашты. Алар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Рус православие чиркәвенең Синодаль бүлеге рәисе Всеволод Чаплин, Татарстан митрополиты Анастасий атакай, Татарстан мөфтие урынбасары, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, К(П)ФУ ректоры Илшат Гафуров, Россия Фәннәр академиясенең Шәрыкне өйрәнү институты җитәкчесе Виталий Наумкин һәм башкалар бар иде.

Рәсми документка кул куелганчы дин һәм фән әһелләре чарага җыелганнарны сәламләп, төрле конфессия вәкилләре арасында татулыкны саклау һәм уку-укыту, фән өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу, төрле диннәрне өйрәнү мөһимлегенә басым ясадылар. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышында республикабызда динара татулык хөкем итүен ассызыклады. Төрле диннәр өчен рухи кыйммәтләр бергә, аларны халыкка җиткерүдә төрле конфессия вәкилләренең уртак хезмәттәшлек коруы әһәмиятле. Камил хәзрәт Изге китап сүзләрен искә төшереп: "Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә: **"Мин кешеләрне төрле халыклар итеп яралттым - бер-берегезне өйрәнер өчен *("Бүлмәләр" сүрәсе, 13 нче аять)***. Башкаларны өйрәнү ул - гыйлем туплау", - диде.

Чараның рәсми өлешеннән соң төрле уку йортлары галимнәре, мөгаллимнәре катнашында түгәрәк өстәл уздырылды.

# ТАТАРСТАН МӨФТИЕ МӘСКӘҮДӘ МӘХӘЛЛӘЛӘР ТӘҖРИБӘСЕНӘ БАГЫШЛАНГАН КОНФЕРЕНЦИЯДӘ КАТНАШТЫ

***Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәүдә "Этноконфессиональ мөнәсәбәтләрне җайлауда һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүдә дини мәхәлләләр тәҗрибәсе" дигән темага багышланган конференциядә катнашты. Әлеге чараны Халыкара Ислам миссиясе, Мәскәү мөфтияте, Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды Россия Иҗтимагый Палатасында оештырды.***

Көн дәвамында күренекле дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре яшьләрне тәрбияләүгә, төрле дин вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылышлы сорауларны тикшерделәр.

Татарстан мөфтие үз чыгышында нәзарәтнең яшь буын белән эшләү, социаль проектларны тормышка ашыру тәҗрибәсен уртаклашты. Камил хәзрәт яшьләрнең йогынтыга тиз бирелүен билгеләп узды. "Татарстан мөфтияте яшьләр рухын ныгыту максатыннан билгеле бер эшләрне тормышка ашыра. Хәзерге вакытта Татарстан дини мәгарифенең дәрәҗәсен үстерү өчен гамәлләр кылына. Моның өчен яңа уку программалары әзерләнә, дөньякүләм танылган галимнәр лекцияләр укырга чакырыла, уку йортлары китаплар белән тәэмин ителә. Мәдрәсәләр өчен бердәм дини уку-укыту стандартлары әзерләү өчен Уку-укыту методик берлеге төзелде", - диде хәзрәт. Шулай ук ул яшь буынга традицион рухи кыйммәтләрне сеңдерү мөһимлеге турында да сөйләде. Бүгенге көндә Татарстан мәдрәсәләрендә татар галимнәрен актив өйрәнәләр, иске татар телен өйрәтүче түгәрәкләр оештырыла, татар дин белгечләре китаплары басыла. Моннан тыш Татарстан мөфтияте яшь имамнарга ярдәм итүдә зур адым ясады, аларга матди ярдәм күрсәтелә башлады.

Мөфти фикеренчә, бүгенге көндә федераль күләмдә уртак бер идеология һәм максат җитмәве сизелә. "ТР МДН исә Татарстан мөселманнары өммәте алдына хәнәфи мәзһәбе һәм матуриди гакыйдәсенә таянган традицион ислам идеологиясен куйды. Бу безнең иң мөһим эшебез. Татарстанда рухи яктан үсәргә бар мөмкинлекләр бар. Татарстанда булдырылган һәм саклап килгән толерантлык күренеше дөнья күләмендә "Татарстан моделе" исеме белән билгеле", - диде мөфти хәзрәт. Үз чыгышында ул яшьләрдә зур кызыксындыру тудырган һәм 145 татар галиме урнаштырылган интернет китапханә ("Darul-Kutub"), виртуаль мәдрәсә ("Baitul Hikmah"), беренче мәртәбә уздырылган онлайн фестиваль-хакында да әйтте.

Сөйләшүдә катнашучылар арасында Мәскәү мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов, ТР МДН аппараты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, Россия Иҗтимагый Палатасы әгъзалары һәм башкалар бар иде.




## АНТАРКТИДАДА БЕРЕНЧЕ АЗАН ЯҢГЫРАЯЧАК

***Рус география җәмгыяте экспедициясендә катнашучылар Коръән һәм Казан Изге Ана иконасын Антарктидага илтәчәкләр.***

ТР МДН исеменнән дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров Кол Шәриф мәчетендә "Антарктида-100" экспедициясе вәкилләренә Татарстан җитәкчелеге ярдәме белән нәшер ителгән Изге Китапны тапшырды. Экспедициядә катнашучылар аны ТР МДН исеменнән котыпчыларга тапшырачак. "Беренче басма Коръәннең Казанда татарлар тарафыннан басылып чыкканын без барыбыз да беләбез, Изге Китапның ул нөсхәләрен Россиядә генә түгел, Урта Азиядә һәм бөтен гарәп дөньясында укыганнар. "Коръән" сүзе һәрчак укый торган дигән мәгънәгә ия. Менә хәзер аны Антарктидада да укыячаклар, анда беренче тапкыр азан әйтеләчәк, без - мөселманнар өчен чын мәгънәсендә тарихи вакыйга бу", - диде Нияз хәзрәт, Коръәнне тапшырганда.

# ӘЛМӘТТӘ РИЗАЭДДИН ХӘЗРӘТ ФӘХРЕТДИННЕ ИСКӘ АЛДЫЛАР





***Әлмәт районының Кичүчат авылында беренче мәртәбә "Ризаэддин Фәхретдин: рухият, мәдәният һәм мәгърифәт" дип аталган конференция оештырылды.***

Танылган дин әһеле һәм галим Р. Фәхретдиновның 155 еллыгына багышланган фәнни-дини чара дин әһелләрен, мөгаллимнәрне, галимнәрне һәм җирле хакимият вәкилләрен җыйды. Алар арасында татар халкының күренекле шәхесләре һәм галимнәре Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, Фаяз Хуҗин бар иде. Чарада нәзарәтнең фән һәм уку-укыту бүлеге җитәкчесе Айдар Карибуллин, район мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов, Уфаның "Ихлас" мәчете имам-хатыйбы Мөхәммәт хәзрәт Галләм катнашты.

Чара Әлмәт районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтҗановның Коръән укып, дога кылуы белән башланып китте. Конференцияне оештыручы, Р.Фәхретдинов мемориаль музее директоры Диләрә Галләмова ике атна элек Уфада булулары хакында әйтеп, анда җылы каршы алулары өчен Мөхәммәт хәзрәткә рәхмәтен белдерде.

Конференциянең икенче өлешендә төрле секцияләргә бүленеп, җирлекнең дини тормышы, Р.Фәхретдиннең рухи мирасы белән таныштылар.

Шулай ук фәнни чарада катнашучылар Кичүчат авылы мәчетендә һәм Р.Фәхретдин музеенда булдылар.

# Биектау авылында төзеләчәк мәдрәсәгә нигез салынды

***Биектау авылында төзеләчәк мәдрәсәгә беренче нигез ташы салынды. Әлеге төзелә башлаган яңа корылма мәчеткә якын гына урнашкан.***

Нигез ташы салу вакыйгасында район мөселманнары, кунаклар катнашты. Алар арасында Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов, Биектау муниципаль районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин һәм башкалар бар иде. Биектау мөхтәсибе Тәлгать хәзрәт Гайфуллин һәм районның башка имамнары нигез ташын салганда, олуг эшкә фатиха биреп, Коръән аятьләре укыдылар.

# МАРАТ КАБАЕВ МӨСЕЛМАН ЭШКУАРЛАРЫ АССОЦИАЦИЯСЕН ҖИТӘКЛИ

***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Эшкуар мөселманнар ассоциациясенең коммерциягә булмаган партнерлыгын гамәлгә куючыларның җыелышы үткәрелде. Җыелышта оешманың яңа президенты билгеләнде. Бу вазифаны хәзер Марат Кабаев башкара.***

Татарстан мөфтие яңа җитәкчегә ислам бизнесы һәм финансларын үстерү һәм Россия мөселман эшкуарларын берләштерү һәм аларга чит илләрдәге дин кардәшләре белән элемтәләр кору буенча яңа максатлар куйды. Мөфти мөселман эшкуарлар ассоциациясе зур хәйрия проектларын оештырыр дигән өметен белдерде.



# ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫНА КИЛЕГЕЗ!

Диния нәзарәтенең татар җәмәгатьчелеге белән эшләү бүлеге "Зәкят" фонды белән берлектә нәзарәт бинасында **(3 нче катта)** һәр атнаның пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә ***16.00 сәгатьтә*** татар теленә өйрәтү курслары башлап җибәрә. Курсларда Казан шәһәренең мәчетләрендә эшләүче хезмәткәрләрне һәм шулай ук татар телен өйрәнергә теләгән барлык кардәшләрне көтеп калабыз. Курс 3 ай дәвамында барачак, уку тәмамлангач сертификат бирү каралган. Теләге булган кешеләргә намаз укырга өйрәнү мөмкинлеге дә бар.

***Курсларга язылу өчен 8 (927) 413-82-44 телефоны буенча шалтыратырга кирәк. Сезне көтеп калабыз! Рәхим итегез!***

# "ЗӘКЯТ" ФОНДЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ХОСПИСТА БУЛДЫ

***Ноябрь урталарында ТР МДНнең "Зәкят" хәйрия фонды хезмәткәрләре хосписка барды. Аларның бергә икенче мәртәбә килүләре. Бу юлы авыру балалар һәм аларның әти-әниләре белән РИИ студентлары Руслан Вәйселов һәм Илнур Шакиров аралашты. Алар Коръән аятьләренең шифасы хакында вәгазьләр сөйләделәр. Очрашу кысаларында ата-аналарны кызыксындырган күп сандагы сорауларга җавап бирделәр. Мондый дини эшчәнлек тәҗрибәсе шәкертләрнең үзләрен дә бик дулкынландырды. Шулай ук фонд хезмәткәрләре сабыйларны тәм-томнар белән дә сыйлады.***

Бүгенге көндә Татарстанның беренче балалар хосписында төрле милләттән булган 20 бала дәвалана. Алар янына атна саен төрле дин вәкилләре килә. Бу аралашу балаларның ата-аналарына бик зур психологик ярдәм булып тора. Алар тәүлек дәвамында балалары янында, шунлыктан мәчеткә яки чиркәүгә барырга вакытлары да җитми.

# КАЗАН-УФА ЮЛЫНДА МӘЧЕТЕ ТӨЗЕЛӘ

***Уфага кылган сәфәреннән кайтышлый мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстанның Актаныш һәм Минзәлә районнары чигендә урнашкан "Нур" мәчетенә тукталды һәм мәчетне салган Ренат Нуртдинов, Актаныш районы*** имам-мөхтәсибе Руслан хәзрәт Мортазин белән очрашты.

Әлеге иман йорты Казан - Уфа юлы өстендә, Татарстанның Актаныш районына караган Пучы һәм Әнәк авыллары арасында мосафирларга гыйбадәт кылыр өчен салынды һәм 2012 елның июнь аенда ачылды. Изге йорт "Протон" оешмасы генераль директоры Ренат Нуртдиновның игәнә акчасына төзелде.

Камил хәзрәт юл мәчетендәге күркәм тәртип һәм гыйбадәтләр кылырга барлык шартлар булуы хакында әйтеп, Ренат әфәндегә мөселманнарга кылган эшләре өчен рәхмәтен белдерде. Ренат Нуртдинов исә мөфтигә мосафирлар өчен тагын бер мәчет төзи башлавы хакында әйтте. Төзелеп килүче Актаныштагы икенче юл мәчете шулай ук Казан - Уфа трассасында - Татарстаннан Башкортстан җиренә кергәнче, районның Чишмәбаш авылыннан ерак түгел җирдә урнашкан. "Агач мәчет төзелеше киләсе елда дәвам итәчәк һәм, Алла боерса, мөселман мосафирларга озын сәфәрләре вакытында тукталып гыйбадәтләр кылырга тагын бер мөмкинлек булыр", - дип сөйләде Ренат Нуртдинов.

# ҮЛЕМ ТУРЫНДА

**"Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, йөкләмәләр йөкләп, сезне сынамак өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белмәк өчен, Ул һәрнәрсәдән өстен вә ярлыкаучы"** ***("Мүлек" сүрәсе, 2 нче аять).***

Хөрмәтле дин кардәшләрем!

Бүген без ахирәткә илтә торган юл турында сөйләшәчәкбез. Бу юлның фани дөньяда ук башлануын әйтәсем килә. Аны ике төргә бүлеп карарга була:

а) кыска юл,

б) озын юл.

Кыска юл турында Аллаһы тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: **"Ул - Аллаһ, сезгә җирне йөрергә уңай кылды, ул җирнең җилкәсендә йөрегез, теләгән җирендә яшәгез, вә ул җирнең хәләл ризыкларын ашагыз, вә үлгәннән соң терелеп бармак Аллаһ хозурынадыр"** ***(Мүлек" сүрәсе,15 нче аять).***

Коръәннең икенче бер аятендә болай диелә: **"Ий, адәм баласы, тәхкыйк син Раббыңа юлыгу өчен гамәлендә, ягъни күбрәк гөнаһ эшләрдә тырышу илә тырышасың, ягъни синең кылган һәр эшең Аллаһка күрсәтер өчендер, Кыямәт көнендә гамәлләреңә очрарсың"** ***(Иншикак" сүрәсе , 6 нчы аять).*** Коръәннең бу аяте кешегә аның иртәме-соңмы Аллаһы тәгаләгә кайтачагын әйтә. Шул сәбәпле без һәрвакыт үлемгә әзер булырга тиешбез.

Аллаһы тәгалә колының җанын алырга теләсә, үлем фәрештәсе Газраилгә болай ди: "И, Газраил! Башка фәрештәләр белән бергә колым янына бар һәм аны дөнья мәшәкатьләреннән азат ит". Шуннан соң Газраил, хуш исләр алып, фәрештәләр белән бергә Аллаһы тәгаләнең колы янына китә. Килеп җиткәч, ул аңа сәлам бирә һәм болай дип сорый: "Син көнбатыштан алып көнчыгышка кадәр ил гиздең. Әйт әле безгә нәрсә белән килдең?" Аллаһы тәгалә колы болай дип җавап бирер: "Аллаһы тәгалә белән ант итәм! Кеше бу дөньяда мең ел дәвамында байлыкта хәсрәтсез һәм мәшәкатьсез тормыш кичерсә дә, кабергә кергәндә аңа байлыгы да, матурлыгы да булыша алмаячак".

Бу хакыйкать: Аллаһы тәгалә кануннары буенча яшәгән мөселман кешесенә үлгәндә болай диеләчәк: "И, гүзәл һәм камил җан! Бу тәннән җиңеллек белән чык". Бу мизгелдә җан тәннән җиңел чыга, ә моның өчен җаваплы фәрештәләр, җанны алып, аны җиденче күккә күтәрәләр. Җиденче күктә аларны башка фәрештәләр белән бергә Җәбраил (галәйһиссәләм) каршы ала һәм җанны Аллаһы тәгалә янына алып баралар. Җан Аллаһы тәгалә каршына килеп җиткәч, Ул әйтәчәк: "И, фәрештәләрем! Бу гүзәл җанны алыгыз да, чәнечкесез агачлар үсә торган бакчаларга кертегез, анда банан тәлгәшләре астында елгалар чылтырап ага, шул елга ярларында алар җитешлектә һәм ләззәттә ятарлар". Шуннан соң Аллаһы тәгалә 500 фәрештәгә әмер бирер: "Бу кешенең йөртына барыгыз һәм кайгыларын уртаклашыгыз".

Үлгән кешенең тәнен юалар, аны я уң, я сул якка әйләндереп куялар. Ул кыймылдый да алмый, кулына бер нәрсә ала алмый, торып та китә алмый. Аның күзләренең нуры сүнгән. Авызы ярымачык, тәне ялангач... Ий, Адәм баласы! Тере чагыңда яныңа кем дә булса килеп, сине чишендереп, бу хәлдә калдыруын теләр идеңме? Инде менә киемеңне салдырып, сине юарга әзерләделәр.

"Ий, кеше! Тәүбәгә кил! Үлем бик якын. Теләкләреңне кире как, чөнки җаның ачу белән каткан".

"Ий, кеше! Бар мөлкәтең һәм байлыгың калачак. Кеше бу дөньядан бер кисәк кәфен белән генә китә".

Хөрмәтле кардәшләрем! Үлгән кешеләрнең тәнен юучы кеше сезнең яки минем тәнне юа дип күз алдына китерик. Һәм сезнең нәрсәне дә булса төзәтергә көчегез дә, мөмкинлегегез дә юк. Байлыгыгыз да, хокукыгыз да юк.

Балаларыгыз һәм якыннарыгыз кайда? Сезне беркем дә күрми - дусларыгыз да, балаларыгыз да, ә сез мәетләрне юа торган ябык бүлмәдә ятасыз.

Коръәннең менә бу аятьләрен игътибар белән укып, мәгънәләренә төшенеп карыйк. Аллаһы тәгалә Коръәни-Кәримдә нәрсә дип әйтә соң? **"Әгәр үлемгә хәзерләнгән кешенең җаны бугазына җитсә, сез шул вакытта аңа карап сорарсыз. Ул кешенең хәлен белү өчен сезгә караганда Без белем вә кодрәтебез белән аңа якынраkбыз, ләкин ул кешегә килгән хәлне сез белмисез һәм күрмисез. Әгәр Безнең хозурыбызда хөкем ителми торган булсагыз, ягъни кешенең үлеме Аллаһтан түгел, үләбез дә бетәбез дисәгез, ул кешене үлемнән коткарып дөньяда яшәү өчен кире кайтарыгыз, әгәр Аллаһтан башка эш кыла алабыз дигән сүзегез дөрес булса! Әгәр ул үлгән кеше Аллаһка якын кешеләрдән булса, аңар рәхәтлек вә хуш исле гөлләр арасында яхшы нигъмәтләр вә нәгим җәннәтедер. Әмма уң тараф кешесе булса. Сиңа җәннәттәге уң тараф юлдашыңнан сәламдер. Әгәр ул үлгән кеше Коръәнне вә Пәйгамбәрне ялган диюче адашкан кеше булса, аның сые җәһәннәмнең кайнар суыннандыр. Вә җәһәннәм утының яндырулыдыр. Тәхкыйк бу зикер ителгән нәрсәләр якын булган хактыр. Олуг булган Раббыңның исемен мактап тәсбих әйт!"** ***("Вакыйга" сүрәсе, 83-96 нчы аятьләр).***



Я, Раббым! Синең сыйфатларың камил. Ий, Көч һәм Кодрәт иясе, Аллаһым! Син җитешсезлекләрдән азат һәм бар яктан да камил. Ий, Аллаһ! Син "бул" дисәң, һичшиксез булачак. Синең сыйфатларыңның камил булуы - хакыйкать.

Ий, Адәм баласы! Хәзер син киемсез. Тәнеңдә кәфеннән башка бернәрсә дә юк. Тере чагыңда син көн саен төрле киемнәр кия идең, шул ук вакытта синең эчке дөньяңда тынычлык юк иде.

Мәңгелек бары тик Аллаһы тәгалә генә! Ул гына бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Аннан башка беркем дә мәңге яшәмәячәк. Ул бирүче, Ул киртә куючы, Ул файда һәм зыян китерүче, Ул бар нәрсәнең Хуҗасы. Аңа тиңнәр юк.

Ий, Адәм баласы! Игътибар ит: "Син туганда елагансың, ә кешеләр син тууага шатланганнар, көлгәннәр. Исән чагыңда шундый гамәлләр кылырга тырыш, син үлгәч, барысы да еларлык, ә син шатланырлык булсын".

Ий, Адәм баласы! Тәнеңне юучы корсагыңа баскач, син бернинди аваз да чыгара алмаячаксың. Авыр хәлдә калган ятимнәр белән нәрсә булыр?

Күзләрең күрми - аларга нәрсә булган? Колакларың ишетми. Йөрәгеңдә нигә курку юк? Тормышың белән нәрсә булды? Нигә анда гыйбадәт кылуга урын юк?

Ий, кеше! Кем син? Бары тик җан һәм тән. Синең җаның - Аллаһы тәгалә сере, ә тәнең - бер уч туфрак. Ә хәзер җан һәм тән кыйммәте турында уйлагызыз... Җан беркайчан да юкка чыкмаячак. Чөнки җан - Аллаһы тәгалә әмереннән. Ул юкка чыга алмый. Аңа ләззәттә яки газапта булырга язган.

Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә безгә болай дип тапшыра:

"Җан тәннән чыккач, җаннар җыелган урынга китәчәк. Килеп җиткәч, башка җаннар аның янына ул килгән дөньяда булган яңалыкларны ишетер өчен җыелырлар". Шуңа күрә сездән алда киткән җаннарга игелек кылыгыз.

Ий, тереләр! Коръәни-Кәримне үзегезгә юл күрсәткече итеп, ә Пәйгамбәребез сөннәтен таҗ итеп алыгыз.

Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.) сахәбәләреннән Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) һәм Сад бин Джусама (радияллаһу ганһү), Аллаһы тәгалә каршында бер-берсенә болай дигәннәр: **"Арабыздан беренче булып үлүче, төшкә кереп, үлгәч нәрсәләр белән очрашуы турында сөйләр".** Беренче булып Сад бин Джусама (радияллаһу ганһү) үлә. Ләкин бер ел узгач та Малик (радияллаһу ганһү) аны төшендә күрми. Көннәрдән бер көнне Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) Сад бин Джусаманы (радияллаһу ганһү) төшендә күрергә ниятләп йокларга ята. Һәм бу юлы күрә. Төштә Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) Сад бин Джусамадан (радияллаһу ганһү) ни сәбәпле бер ел буе төшенә килмәвен сорый.

- Мин Аллаһы тәгаләнең сорауларына хәзер генә җавап биреп бетердем, - ди ул.

Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) сорый:

- Миңа нинди дә булса йомышың бармы?

Сад бин Джусама (радияллаһу ганһү) болай ди:

- Әйе, бар. Мин бер кешедән 3 дирһәм бурычка алып торган идем, өйлә намазыннан соң бирергә тиеш идем, ләкин иртәрәк үлеп киттем. Минем йортыма бар, махсус урында акча табарсың. Акчаны алып, мин бурычлы кешегә бир һәм болай дип әйт: "Сиңа Садның бурычын алып килдем, ул исәпхисабын кәтә һәм җәннәткә керә алмый".

Уянгач, Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) Сад бин Джусамага (радияллаһу ганһү) бурычка биргән кеше янына юл тота һәм аннан сорый:

- Исән чагында Сад бин Джусама сиңа бурычлы идеме?

- Әйе, ул миннән өч дирһәм алып торган иде.

Шуннан соң Ауф бин Малик Сад бин Джусама йортына юл тота. Килеп җиткәч, кирәргә рөхсәт сорый. Рөхсәт алгач, төшендә Сад күрсәткән җирдә өч дирһәм таба һәм Садка бурычка биргән кешегә барып, бурычны аңа

кайтара да болай ди:

- Мин синнән Аллаһы тәгалә каршында Садны кичерүен соравыңны үтенәм. Чөнки Сад сиңа бурычын кайтармаганга күрә җәннәт капкалары янында керә алмыйча тора".

Габдулла бин Рабах (радияллаһу ганһү) улы сөйли: "Мут'а көрәше вакытында минем әтием һәлак була. Мин шул көнне үк гөнаһ кылдым һәм Аллаһы тәгалә кушканга каршы чыктым. Шул ук төнне мин әтиемне төштә күрдем. Ул миңа болай диде: "Улым, ни сәбәпле син Аллаһы тәгалә кушканга каршы чыгып гөнаһ кылдың? Син бу гөнаһны кылганга миңа башка әрвахлар алдында оят".

Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) болай дигән: "Үлгән кеше якыннары һәм туганнары кайгырып елаганда, аның янына фәрештә килеп, маңгаена сугып, сораячак: "Син чыннан да алар сөйләгән кебек идеңме?" Шуңа күрә үзегезнең үлгән якыннарыгыз өчен Аллаһы тәгалә алдында куркыгыз".

Безнең замандагы кебек үк, Аллаһы тәгалә Пәйгамбәре (с.г.в.) заманында хатын-кызлар якыннары үлгәч, бик елаганнар. Бер хатын үлгән кеше өстендә кычкырып елаганны күргәч, Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: "Бу хатын тәүбәгә килмичә үлсә, Кыямәт көнендә, үлгән кеше өстендә кычкырып елаган, киемен һәм чәчләрен йолкыган, үзен тырнаган өчен, йөзе кара, ә күзләре зәңгәр булачак. Фәрештәләрнең берсе аны Аллаһы тәгалә янына алып киләчәк. Аллаһы тәгалә әйтәчәк: "Дөньяда чагыңда син үлгән кеше өстендә кычкырып еладың, җәһәннәмгә кер дә, шулай ук анда булучы өстендә ела".

> ***Җан Аллаһы тәгалә каршына килеп җиткәч, Ул әйтәчәк: "И, фәрештәләрем! Бу гүзәл җанны алыгыз да, чәнечкесез агачлар үсә торган бакчаларга кертегез, анда банан тәлгәшләре астында елгалар чылтырап ага, шул елга ярларында алар җитешлектә һәм ләззәттә ятарлар".***

Хөрмәтле кардәшләрем! Җан турында нәрсә белсәк, сезгә бүген шуны сөйләп бирдек. Ә балчыктан ясалган тәнгә килгәндә исә, биология, физика һәм химия өлкәсендәге галимнәр болай диләр: "Әгәр дә кеше тәнен алсак һәм аны молекуляр кисәкчәләргә бүлсәк, без аның май, углеводлар, фосфор, магний, тимер, известь һәм судан торуын күрербез. Кеше организмындагы майдан җиде кисәк сабын ясарга була. Углеродтан бары тик ун карандаш, магнийдан диареягә каршы бары тик бер төймә дару ясап була, ә организмдагы известь бер тавык оясын буярга, күкерт берничә борчаны үтерергә җитә. Тимердән уртача зурлыктагы бер кадак ясап була. Әлеге әйберләрнең барысын җыеп базарга алып чыгып сатсак, зур булмаган табыш алачакбыз. Бу - хакыйкать. Ий, үз тәненең колы булган кеше! Үз тәнеңне карарга күпме көч түгәсең, талчыгасың. Ахыры барыбер күңелсез булган нәрсәдән файда күрергә телисеңме?"

Җаныңа игътибар ит һәм аны тәрбияләргә тырыш. Чөнки тәне булганнар түгел, җаны булганнар кеше була.

Ике куллап Аллаһы тәгалә җебенә ябыш. Ул гына сине башкалардан яклап калачак.

Бөтен шатлык һәм зирәклек җанда. Шул сәбәпле Аллаһы тәгалә үзенең Илчесе Мөхәммәд Пәйгамбәргә (с.г.в.) болай дип: "Үлгән кеше батып баручы кешегә тиң. Ул һәрвакыт якыннарыннан һәм туганнарыннан аның өчен дога кылуларын көтә. Дога аңа барып ирешкәч, ул аңа бу дөньяда булган бар нәрсәдән дә кыйммәтрәк".

Түбәндәге хәдискә карыйк: "Мөселман кешесе зиратка килеп, анда ятучыларга сәлам бирсә, алар аның сәламенә җавап бирәләр һәм ул кеше киткәнче аңа карата яхшы мөнәсәбәттә булалар".

Шулай ук Пәйгамбәребез (с.г.в.) башка хәдистә болай ди: "Арагыздан берегез зиратка керсә һәм анда "лә иләәһә иллә Аллаһ" дип әйтсә, әрвахлар аңа җавап бирәчәкләр: "Син бу сүзләрнең кыйммәтен белсәң, аларны кабатлаудан беркайчан да туктамас идең".

Бервакыт бер кеше үлгән абыйсының каберен карарга зиратка китә. Анда ике рәкагать намаз кыла. Намаздан соң аны йокы баса. Төшендә аның янына кәфенгә теренгән абыйсы килә. Билгеле булганча, төш - җаннарның очрашу урыны. Абыйсы аннан сорый:

- Йоклап киткәнче, син нәрсәләр эшләдең?

- Мин намаз кылдым.

- Әгәр дә Аллаһы тәгалә безгә монда ике генә рәкагать намаз кылырга рөхсәт итсә дә, бу безнең өчен сезнең дөньядагы барлык нәрсәдән дә яхшырак булыр иде.

- Сез бит теге дөньяда. Анда без кылган гамәлләр турында билгелеме?

- Әйе, билгеле, ләкин без бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Сез исә гамәлләр кыласыз, ләкин аларның Аллаһы тәгалә каршындагы дәрәҗәсен күрмисез.

Шул сәбәпле без үлгәннәргә карата хөрмәт күрсәтергә һәм алар өчен Аллаһы тәгаләгә дога кылырга тиеш. Үлгән якыннарына игелек теләгән кеше алар өчен Аллаһы тәгалә алдында күп итеп дога кылсын.

Хөрмәтле кардәшләрем! Тынычлыкка ирешер һәм Кыямәт көнендә җәһәннәм утыннан котылыр өчен безгә нык иман кирәк. Бу өлкәдә без Пәйгамбәребез (с.г.в) сахәбәләреннән үрнәк алырга тиеш. Алар камил һәм нык иман ияләре булганнар, беркайчан да Аллаһы тәгалә юлыннан тайпылмаганнар.

Бервакыт Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.) янына килә:

- Ий, Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.)! Минем улым Малик синең белән бергә көрәшкә китте, бөтен китүчеләр кайтты, минем улым гына кайтмады. Миңа хәзер нишләргә? - ди.

- Ий, Ауф! Хатының белән бергә "лә хәүлә үә лә куватә илләә билләһ" сүзләрен даими кабатлап тор.

Ауф өенә кайта, хатыны аннан Пәйгамбәрнең (с.г.в.) ни дип җавап биргәнен сорый. Ауф:

- Ул безгә "лә хәүлә үә лә куватә илләә билләһ" догасын укырга кушты, - дип җавап бирә.

- Аллаһы тәгалә Илчесе сиңа әйткән - хакыйкать, - ди аңа хатыны.

Шуннан соң алар күп тапкыр "лә хәүлә үә лә куватә илләә билләһ" дип кабатлыйлар.

Төн җиткәч, ишекләрен кемдер шакый.

Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) торып ишек ача һәм сарык көтүе ияртеп кайткан улы Маликне күрә. Ауф:

- Улым, бу нәрсә? - дип сорый.

Малик:

- Мин әсирлеккә эләктем, әти. Мине чылбырлар белән богауладылар. Ничек кенә тырышсам да, ычкына алмадым. Кинәт богаулар бушый башлады. Мин бик шатландым. Бераз вакыт узгач, тимер богаулардан азат булдым. Мәҗүсиләрдән ганимәт (трофей) булаpак менә шушы сарыкларны алдым.

> ***2. "Син туганда елагансың, ә кешеләр син тууага шатланганнар, көлгәннәр. Исән чагыңда шундый гамәлләр кылырга тырыш, син үлгәч, барысы да еларлык, ә син шатланырлык булсын".***

Ауф бин Малик:

- Улым, син булган җирдән безнең йорт арасы еракмы? Ни рәвешле бер төндә өйгә кайта алдың? - дип сорый.

Малик җавап бирә:

Әтием, мин богаулардан котылгач, мине фәрештәләр күтәреп алып, канатларында өйгә кайтарып куйгандай булды. Мин "лә иләәһә иллә Аллаһ" сүзләрен кабатларга яратам. Эшләрдән буш вакытымда мин бу сүзләрне кабатлыйм. Тормышымның күп өлеше бу сүзләрне кабатлап уза. Бу зикерләр белән минем гөнаһларым бетә. Мин бу сүзләр белән кабергә керәчәкмен һәм Аллаһы тәгалә каршына басачакмын.

Бу сүзләрне ишеткәч, Ауф бин Малик (радияллаһу ганһү) Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына юл тота. Авыз ачарга да өлгерми, аңа Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай ди:

> ***3. "Әгәр дә кеше тәнен алсак һәм аны молекуляр кисәкчәләргә бүлсәк, без аның май, углеводлар, фосфор, магний, тимер, известь һәм судан торуын күрербез. Кеше организмындагы майдан җиде кисәк сабын ясарга була. Углеродтан бары тик ун карандаш, магнийдан диареягә каршы бары тик бер төймә дару ясап була, ә организмдагы известь бер тавык оясын буярга, күкерт берничә борчаны үтерергә җитә. Тимердән уртача зурлыктагы бер кадак ясап була..."***

- Шатлан, Малик! Аллаһы тәгалә синең турыңда Коръәни-Кәримнең бу аятьләрен иңдерде: **"Берәү Аллаһка гөнаһлы булудан сакланса, ул кешегә Аллаһ дөньяда һәм ахирәттә хәсрәтле булудан котылу юлын ачар. Дәхи ул кешене Аллаһ уйламаган җирдән ризыкландырыр. Бер кеше үзен, вә барча эшен Аллаһка тапшырса, аның хаҗәтләрен үтәргә Аллаһ җитәдер. Тәхкыйк Аллаһ Үзенең эшләрен җиренә җиткерүче, әлбәттә, Аллаһ һәрнәрсәгә чик үлчәү куйды" *("Талак" сүрәсе, 2-3 нче аятьләр).***

Тагын бер гыйбрәтле хәлне сөйлисем килә. Ул - сахәбәләрнең берсе булган, Әбү Талха (радияллаһу ганһү) хатыны Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә) турында.

Өмме Сүләйманең (радияллаһу ганһә) бары тик бер баласы була. Бервакыт бала авырый башлый. Әбү Талха баласын үбеп, эш эзләргә чыгып китә. Ул чыгып китеп бераз вакыт узгач, бала үлә. Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә), баланың гәүдәсен юып, кәфенгә төрә дә җеназа намазы укып, аны җирли. Баласы үлгәч күрсәткән сабырлыгы өчен Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә) Аллаһының рәхмәтенә өметләнә. Әбү Талха (радияллаһу ганһү) кайткач, улының кайда булуын сорый. Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә): "Бу төнне балабыз бик тыныч йоклады, бер дә газапланмады", - дип җавап бирә. Шуннан соң ул иренә ашарга әзерли. Ашагач, алар йокларга яталар. Берни дә белмәгән Әбү Талха (радияллаһу ганһү) таң атканчы торып, госел коена һәм Өмме Сүләймагә болай ди: "Иртәнге намазга киткәнче улымны үбәсем килә". Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә) нәрсә әйтергә дә, нәрсә эшләргә дә белми һәм болай ди:

- Ий, Әбү Талха! Минем кәефем юк, мине тынычлыкта калдыр!

Әбү Талха:

- Ий, Өмме Сүләйма… - ди.

Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә) җавап бирә:

- Мин күршеләрдән әманәт алган идем, алар аны кире сорадылар.

Әбү Талха (радияллаһу ганһү) аңа:

- Вакытлыча биргән әманәтне кире сораганга борчылырга ярыймы инде? - ди.

Өмме Сүләйма (радияллаһу ганһә):

- Аллаһы тәгалә сиңа биргән әманәтне алса, син борчылырсыңмы? Аллаһы тәгалә бездән аны алгач, ни эшли алабыз?

Бу сөйләшүдән соң Абу Талха иртәнге намазга китә, ә намаздан соң Пәйгамбәр (с.г.в.) янына килеп, хатыныннан зарлана: "Ий, Аллаһы тәгалә Илчесе (с.г.в.)! Балабыз үлгән көнне хатыным ничек миңа ризык әзерләп, минем яныма йокларга ята алды икән?" Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) Әбү Талхага түбәндәге доганы укый: "Ий, Әбү Талха! Аллаһы тәгалә үткән төнне сезнең өчен бәрәкәтле итсен!"

Хөрмәтле кардәшләр, сезгә бу доганың нәтиҗәсе билгелеме? Аның нәтиҗәсен бу хәдис тапшыра: "Соңрак Әбү Талханың (радияллаһу ганһү) тугыз баласы туа, алар барысы да корьәнхафиз булалар һәм намазларын Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) мәчетендә укыйлар".

Аллаһы Тәгалә Илчесе (с.г.в.) университетында белем алган кешеләр менә шундый булганнар. Аллаһы тәгаләдән безне алардан ерагайтмавын үтенәм!

***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН, Татарстан Республикасы мөфтие***

# ПӘЙГАМБӘРЛӘРГӘ ЫШАНУ

**Пәйгамбәр дип Аллаһы тәгаләдән вәхи алган һәм тугры дингә өндәгән кешеләрне әйтәләр. Пәйгамбәрләрне кешеләр арасыннан Аллаһы тәгалә Үзе сайлап ала. Берәү дә үз теләге белән яки тәкъвалыгы аркасында гына пәйгамбәр була алмый. Мөселманнар Аллаһы тәгаләнең барлык пәйгамбәрләренә дә һәм аларның бер аллалыкка өндәүләренә ышанырга тиеш. Адәм галәйһиссәләм - беренче пәйгамбәр, ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм соңгы пәйгамбәр булган.**

Коръәндә исемнәре түбәндә китерелгән пәйгамбәрләр искә алына (җәяләр эчендә аларның Библиядәге русча исемнәре күрсәтелгән): Адәм (Адам), Идрис (Енох), Нух (Ной), Ибраһим (Авраам), Альяс (Елисей), Исхак (Исаак), Исмәгыйль (Измаил), Салих, Зәкәрийя (Захария), Әйүп (Иов), Муса (Моисей), Шогаип (Иофор), Дауд (Давид), һарун (Аарон), Йосыф (Иосиф), һуд, Лут (Лот), Ильяс (Илия), Зөлкифел, Яхъя (Иоанн Креститель), Сөләйман (Соломон), Гозаир (Ездора), Гайсә (Иисус), Юныс (Иона) галәйһиссәләмнәр һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм. Кайберәүләр Коръәндә искә алынган Зөлкарнәйн, Хозер, Локман һәм Йушагны да пәйгамбәрләр рәтенә кертә, ә башкалар аларны тәкъвалардан саный. Коръәндә барлык пәйгамбәрләр дә искә алынып бетмәгән, аларның исәбен бары тик Аллаһы тәгалә Үзе генә белә.

### ПӘЙГАМБӘРЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЛАРЫ

Кешеләр тугры юлдан тайпылып, Раббыбыздан башка берәүгә яисә башка нәрсәләргә табына башлаган саен, Аллаһы тәгалә аларга яңа пәйгамбәрләр җибәрә торган булган. Ялгышкан кешеләр пәйгамбәрләргә иярсен өчен, Аллаһы тәгалә пәйгамбәрләрне күркәм сыйфатлар белән баеткан:

Дөреслек. Пәйгамбәрләр гомерләрендә бер тапкыр да ялган сөйләмәгәннәр, беркайчан да алдаламаганнар һәм хыянәт итмәгәннәр.

Ышанычлылык. Пәйгамбәрләргә һәрвакыт ышанырга мөмкин булган, чөнки алар беркайчан да кешенекенә кул сузмаганнар.

Гөнаһсызлык. Аллаһы тәгалә пәйгамбәрләрнең барысын да төрле гөнаһлардан саклаган. Хәтта пәйгамбәрлек вазыйфаларын үти башлаганчы ук та алар гөнаһ кылмаганнар һәм диндар, тәкъва кеше буларак абруй казанганнар. Бер генә пәйгамбәр дә, пәйгамбәр булганчы, мәҗүси булмаган. Алар Аллаһы тәгаләнең барлыгына беркайчан да шикләнмәгәннәр һәм потларга табынмаганнар. Аларның берсе дә Аллаһы тәгаләнең иптәшләре яки улы булуына, Аллаһының үзе яралткан нәрсәләренә охшашлыгына һәм башкаларга ышанмаганнар.

Камил акыл. Пәйгамбәрләрнең барысы да акыллы һәм зирәк булган.

Аллаһы тәгаләнең хөкемнәрен җиткерү. Пәйгамбәрләр Аллаһы кешеләргә ирештерергә кушкан һәр хәбәрне, һәр хөкемне үзгәртмичә һәм яшермичә җиткергәннәр, үзләре дә шуларны тугры рәвештә үтәгәннәр.

Моннан тыш, пәйгамбәрләрнең барысы да тышкы кыяфәтләре белән күркәм булганнар. Пәйгамбәрләр башка кешеләр кебек үк ашаганнар да, эчкәннәр дә, йоклаганнар да.

Пәйгамбәрлекләренә дәлил булсын өчен Аллаһы тәгалә аларга могҗизалар күрсәтү мөмкинлеге бирә.

Пәйгамбәрләр - кешеләрнең асыллары, ә аларның иң яхшысы - Аллаһы тәгаләнең соңгы Илчесе - Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм.

### МӨХӘММӘД САЛЛӘЛЛАҺУ ГАЛӘЙҺИ ҮӘ СӘЛЛӘМГӘ ЫШАНУ

Мөселманнар Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең пәйгамбәр һәм Илче булуына ышана. Аны Аллаһы тәгалә барлык кешеләргә - гарәпләргә дә, гарәп булмаганнарга да, җеннәргә дә җибәрә. Аннан соң бүтән пәйгамбәр булмаячак һәм ул тапшырган канун Кыямәт көненә кадәр гамәлдә калачак.

Аллаһы тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә могҗизалар күрсәтү мөмкинлеген бүләк итә. Аның төп могҗизасы - Коръән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм Коръәннең беркайчан да үзгәртелмәячәген әйтеп калдыра. 1400 ел вакыт узса да, Коръәни-Кәримнең бары бер генә варианты билгеле.

Могҗизалардан тыш, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә шәхесенең камиллеге, ягъни калебенең камиллеге һәм гамәлләрендәге камиллек дәлил булып тора. Ул - туры юлдан тайчынулар, ялгыш карашлар һәм гөнаһлар хөкем сөргән чорда вәхи иңгән пәйгамбәр. Яһүдиләр Аллаһы тәгаләне Ул яралткан нәрсәләргә тиңләштергәннәр һәм Изге Китапларны үзгәрткәннәр. Христианнар бер-берсенә каршы килүче бик күп карашларны, мәсәлән, өчлеккә һәм Ходайның Үзе барлыкка китергән нәрсәләре белән береккән булуына ышану кебек фикерләрне үзара хәл итә алмаганнар. Гарәпләр потларга табынганнар һәм талаулар белән шөгыльләнгәннәр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) килгәннән соң ялгыш карашлар, бозыклык һәм гөнаһларга урын калмый, бер Аллаһыга ышану һәм Аңа карусыз табыну өстенлек итә башлый.

Моннан тыш, Пәйгамбәребез (с.г.в.) кабиләләргә һәм гаилә кланнарына таркалган һәм һәрвакыт үзара дошманлашып, сугышып торган гарәпләрне берләштерә һәм бербөтен җәмгыять буларак камилләштерә. Гарәпләр исламны кабул иткәннән соң, Пәйгамбәребезне (с.г.в.) яклау өчен берләшәләр, ислам хакына туган җирләрен һәм гаиләләрен калдырып китәләр, мал-мөлкәтләрен һәм гомерләрен дә кызганмыйлар.

*"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән*

---

### ҖИР ТЕТРӘГӘНДӘ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

**Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) җир тетрәү, сил (көчле су ташкыны) һәм давыл кебек казалардан шушы доганы укыган: "Җир тетрәгәндә укыла торган догада хаталар күп, алыштырып куйсак әйбәт булыр иде: "Аллаһүммә-хфәзъни мим бәйни йәдәййә үә мин хальфии үә мин йәмииниии үә гән шимәәлии үә миң фәүкый үә әгүүзү би гәзамәтикә ән әгътәәлә мин тәхти" (Аллаһым! Алдымнан, артымнан, уңымнан, сулымнан, күктән һәм җирдән килә ала торган афәтләрдән мине сакла).** ***(Әбү Дауд: 1177).***

### НАМАЗДА ТӘХРИМ ТӘКБИРЕ ӘЙТҮ

***Малик ибне Хууәйристән (радияллаһу ганһү) шулай риваять кылынган: "Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләм тәхрим тәкбире әйткәндә кулларын колакларына кадәр күтәрә иде".***

***Бу хәдис-шәрифне имам Мүслим һәм Нәсаи риваять кылган.***

***"Гыйбадәт кылуга кагылышлы кырык хәдис" китабыннан***

# АХИРӘТ ПАСПОРТЫБЫЗ ӘЗЕРМЕ?

***Аллаһыга һәм ахирәт көненә инанган чын мөэмин үлемгә һәрвакыт әзер булырга тиеш. Чөнки үлемнең кайчан киләчәге турында беркемгә дә хәбәр бирелмәгән, аның көне һәм сәгате алдан билгеле түгел.***

Мөэмин кеше үлемне җәннәткә керер өчен бер күчеш буларак күрер һәм аны Бөек Аллаһының әмере итеп кабул итәр, соң дәрәҗәдә буйсынган хәлдә каршылар. Шуның өчен ул үзенең бар көче белән хәерле эшләр кылырга тырышып яшәр, Аллаһы тәгаләнең ризалыгын алырга омтылыр. Шуны да онытмаска кирәк: үлемгә хәзерлекле булган кешеләр үз гомерләренең ахырына кадәр өмет белән курку арасында яшәрләр. Аллаһыга һәм ахирәт көненә инанган чын мөэмин, үлем хакыйкатенә ышанганга күрә, җәннәтне өмет итсә дә, үзен кимчелексез дип санамаганлыктан җәһәннәмнән дә куркыр. Коръәни-Кәримдә мөэминнәрнең начар хисаптан куркулары, үз-үзләрен матур итеп тотулары һәм алар ирешәчәк яхшы нәтиҗә шул рәвештә билгеләнгән: **"Раббылары ризалыгын алырга теләп алар сабырлык күрсәтәләр, намазларын кылалар. Без биргән ризыктан инфакъ итәләр, яшерен һәм ачыктан саклананалар, һәм игелек кылып, начарлыктан арылалар. Ахирәтнең гүзәл йорты алар өчен әзердер"** ***("Рәгыд" сүрәсе, 22 нче аять).***

Коръән аятьләрендә тасвирланган куркыныч җәһәннәм мохитен һәм аның газапларын мөэмин һәрвакыт исендә тотар һәм Аллаһыга юнәлер. Һәр мизгелдә үзенең үлем фәрештәләре белән очрашуы мөмкин икәнлеген һич онытмас. Биргән карарларында, эшләгән гамәлләрендә, сөйләгән сүзләрендә гел җәннәткә ирешүне һәм җәһәннәм газабыннан котылуны күз алдында тотар.

Башкарган һәр хәрәкәтнең һәм әйткән һәр сүзнең җәннәткә яки җәһәннәмгә якынлаштырачагын яхшы аңлаган мөэмин, Аллаһының ризалыгына туры килмәгән сүзләрдән һәм эшләрдән һәрвакыт тыелыр. Үзенең һәр мизгелдә үлем белән очрашачагын белеп, һәр мөмкинлектән тагы да күп әҗер-савап лар казана алыр өчен акылын, аң-фикерен ачык тотар; җәннәттә кавышуның тойгы-кичерешләре белән җәһәннәмнән ерак булуга нык лы өметләр белән яшәр... Беркемне дә рәнҗетмәс, хаксызлык эшләмәс өчен бар көчен куяр. Гыйбадәтләрендә ваемсызлык күрсәтмәс, һәрвакыт Раббысының яхшы колы булу гайрәтендә булыр...



Мөэмин һичбер вакытта шул илаһи хәбәрне акылыннан чыгармас: **"Әйт: "Сез үлемнән качсагыз да, ул сезне тотып алачак. Ахырда, күренгәнне һәм яшеренне белгән Аллаһ хозурына китереләчәксез. Аллаһ ни кылганыгыз турында сезгә хәбәр бирәчәк"** ***("Җомга" сүрәсе, 8 нче аять).***

Үлем турында уйлануның файдаларын Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) үзенең хәдис-шәрифләрендә шул рәвешле ачыклаган: *"Үлемне еш рак искә алыгыз, чөнки ул (сезне) гөнаһ эшләүдән тыеп калыр һәм дөньядан ераклаштырыр". "Үлемне иң күп зикер итүчеләр һәм үзләренә килгәнчегә кадәр аңа иң яхшы хәзерләнүчеләр - алар кешеләрнең иң зирәкләре" (Ибне Мәҗәһ, "Зүһд", 31).*

Әйе... Үлемгә һәрвакыт әзер булыр өчен мөэмин гомере буенча "курку белән өмет" арасында яшәр. Хисап көненнән куркып, җәннәткә яки җәһәннәмгә керүне көткән кешеләрнең рухи хәлләрен һич тә хәтереннән чыгармас.

Ахирәт паспортлары әзер кешеләрнең рухи хәлләре әнә шундый булырга тиеш...

***"Мәңгелеккә юл тотучының АХИРӘТ ПАСПОРТЫ" китабыннан***

# КАБАТЛАП ТОРМАСАҢ, КОРЪӘН ТЫШАВЫН САЛГАН ДӨЯДӘН ДӘ ТИЗРӘК "КАЧА"

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршында Коръәнне өйрәнү бүлеге оешуга бер ел тулды. Шушы кыска гына вакыт эчендә ул киң эшчәнлек җәелдереп, мөселман җәмәгатьчелеге арасында шактый танылу алды. Бүлекнең җитәкчесе Илнур хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН белән булган әңгәмәбездә без халыкны кызыксындырган сорауларны күтәрергә тырыштык.**



**– Хәзрәт, быел сентябрь аеннан республикабыз мәчет-мәдрәсәләре каршында коръәнхафизлар түгәрәкләре эшли башлады. Бу түгәрәкләрне оештыру уе ничек туды?**

– Мөфтияттә Коръәнне өйрәнү бүлеге ачылгач, без районнар өчен – Болгарда һәм Казанда Коръән уку конкурслары оештырган идек. Бу конкурс нәтиҗәләре Татарстанда Коръәнне дөрес итеп уку дәрәҗәсенең әле бик түбән икәнен күрсәтте, шуннан соң туган проект инде бу. Без күбрәк балаларга басым ясарга булдык. Казанда, Буа, Нурлат, Әлмәт, Зеленодольск шәһәрләрендә коръәнхафизлар әзерләү түгәрәкләре ачып җибәрдек. Бу – анда Коръән ятлау белән генә шөгыльләнәләр икән, дигән сүз түгел. Ният – беренче чиратта дөрес итеп укырга өйрәнү һәм, әлбәттә инде, мөмкин кадәр ятлау. Хафиз ул – Коръәнне яттан белүче, аны саклый торган кеше. Ә Коръәндә исламның бөтен кануннары бар. Бездә укымышлы кешеләр булса да, Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиевлар дәрәҗәсендәге бөтен дөньяга танылган галимнәр юк. Галим булу өчен, аз дигәндә, Коръәнне яттан белергә, ә аннары гарәп телен камилләштерергә кирәк. Борынгы галимнәр кешедә 4 нәрсә булса гына шәкерт итеп алганнар: бу - әдәп, Корьәнне яттан белү, гарәп телен камил белү, мирас гыйлемен белү.

**– Коръәнхафизлар әзерләү белән бергә сез әле киләчәктә галим булып китәрдәй талантлы балаларны да эзлисез икән.**

– Нәкъ шулай. Алардан киләчәктә имамнар, укытучылар, галимнәр үсеп чыгар, иншә Аллаһ. Безнең бит бүгенге көндә коръәнхафизлар әзерләрлек укытучыларыбыз да бармак белән генә санарлык. Район, шәһәр мәдрәсәләреннән дә, укытучылар җибәрегез, дип сорап торалар. Биналары, бөтен укыту кирәк-яраклары бар, әмма кадрлар юк. Киләчәктә эшне шулай оештырырга кирәк – һәр район, шәһәр үз белгечләрен махсус җибәреп укытсын.

Коръән укуга бик җитди караш булырга тиеш, чөнки бу ислам динендә һәр мөселманга фарыз-гайн булып тора. Аллаһы тәгалә Коръәнне тәртил белән, аңлаешлы һәм ачык итеп, авазларны дөрес чыгарып укырга куша. Без бит намазда да Коръән аятьләре укыйбыз. Аларның мәгънәләрен бозып укысаң, намазың кабул булмый дигән сүз.

**– Дистәләрчә түгәрәкләр ачкансыз, анда укытырга коръәнхафизларны кайдан табып бетердегез?**

– Без аларны РИИ һәм "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаган дипломлы белгечләр арасыннан сайлап алдык. Берничә мәчеттә хатын-кызлар төркемнәре бар. Аларда белем бирүче хафизаларыбыз да Россия ислам институтының коръәнхафизлар бүлеген тәмамлаган белгечләр. Хезмәт хакы түләү мәсьәләсен "Зәкят" хәйрия фонды үз өстенә алды. Ярдәм итәргә теләүчеләр бу ниятләрен әлеге фонд аша башкара ала. ***Благотворительный Фонд "Закят"***

***ИНН/КПП 1655068682/165501001***

***ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012***

***р/с N 40703810662190000765 (Советское отделение N 6669/015 СБ РФ г. Казани)***

***ОСБ БАНК ТАТАРСТАН N 8610 г.Казани***

***к/с: 30101810600000000603***

***БИК: 049205603***

***Юридический адрес: 420111, г. Казань, ул. Лобачевского, д. 6***

**– Коръән ятлау гади кеше өчен көч җитмәслек бик авыр эш кебек тоела хәтта. Аның берәр төрле ысулы бармы?**

– Коръәнне төрле илләрдә төрле ысуллар белән ятлыйлар. Мин үзем, мәсәлән, Төркиядәге ысулны кулландым. Коръән 30 җүздән тора. Һәр көнне бер җүздән берәр бит ятласаң, бер ай эчендә һәр җүздән берәр бит ятлап чыккан буласың. Аннары кире беренче җүзгә әйләнеп кайтып, бер ай элек ятлаганны кабатлыйсың да моңа тагын бер битне өстисең. Шул рәвешле 20 әйләнеш ясап, 20 ай эчендә Коръәнне ятлап та бетерәсең. Әмма ятлап чыктың да булды түгел, гел кабатлап торырга кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Әгәр кабатлап тормасаң, Коръән тышавын салган дөядән дә тизрәк кача", - дигән.

Укуларны без сентябрь аенда башлаган идек. Түгәрәккә йөрүче балалар бик тырышалар. Ярты җүзгә кадәр – егерме бишәр сүрә ятлаучылар да бар. Бу әле беренче генә баскыч. Менә гарәп телен дә өйрәнгәч, ул аны укып фикерли, тулысынча Коръән белән яши башлый. Киләчәктә безнең дә Коръән ятлауны гарәп телен өйрәнү белән бергә алып барырга дигән ниятебез бар. Мин үзем дә Коръәнне укырга өйрәнә башлаганда гарәпчә белми идем. Гарәп телен үзләштергәч, аңлап укый башлыйсың һәм бөтенләй бүтәнчә кабул итәсең.

**– Сез үзегез кайда укыдыгыз?**

– Башта Истанбулда Коръән курсларын тәмамладым. Аннары Россия ислам институтының коръәнхафизлар бүлегендә белем алдым. Пәйгамбәребездән (с.г.в.) нәселдән-нәселгә килә торган иҗазәт дигән документ бар, ул Коръән гыйлемен укырга рөхсәт бирә. Сүриянең Димәшкъ шәһәрендәге Кыйраат мәдрәсәсендә укып, шул таныклыкка ия булдым.

**– Төркиядә коръәнхафизлыкка укып кайткан Мөхәммәт атлы бер малай, без имтихан тотканда мәчет тирәсенә бик күп халык җыелды, хәтта Президент үзе дә килгән иде, дип сөйләде. Безнең яшь коръәнхафизларга да шундый ихтирам казану насыйп булса иде.**

– Халык Коръәннең кадерен, кыйммәтен аңлый башласа, иншә Аллаһ, бездә дә шулай булыр...

***Әңгәмәдәш – Нәүбәһар КӘБИРОВА***

## КАЙСЫ МӘЧЕТЛӘРДӘ КОРЪӘН УКУ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ ЭШЛИ

*Татарстанның мәчет һәм мәдрәсәләре каршында Изге Коръәнне өйрәнү буенча махсус түгәрәкләр оештырылды. Дәресләр ел дәвамында үткәрелә. Әлеге файдалы проект Диния нәзарәтенең Коръәнне өйрәнү бүлеге, "Зәкят" хәйрия фонды, Казан ислам институты каршындагы Корьәнхафизлар әзерләү үзәге һәм "Коръән нуры" хәйрия фонды ярдәме белән тормышка ашырылды. Түбәндә китерелгән мәчет һәм мәдрәсәләргә килеп, теләгән һәркем Коръәнне дөрес итеп укырга өйрәнә ала.*

Өметләләр мәчете (2-нче Азин ур., 1 нче в йорт, мөгаллимнең телефоны: 89272495061);

Кабан арты мәчете (Һ.Такташ ур., 26 нчы йорт, мөгаллимнең телефоны: 89510604745);

Гаилә мәчете (Җ.Фәйзи ур., 3 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89655967011);

Апанай мәчете (К.Насыйри ур., 27 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89375279494);

Нурулла мәчете (Мәскәү ур., 74 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89375279494);

Ярдәм мәчете (Серов ур., 4 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89276731306);

Әмәт мәчете ( Дачная ур., 3 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89178555529);

Әниләр мәчете (Газ ур., 18 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89093077855);

"Жемчужина веры"мөселман йорты (Вишневский ур., 12 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89061133986);

Әтиләр мәчете (Кояшлы бист., Күлбаш ур., 13 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89274077353);

Буа мәдрәсе (Буа шәһ., К.Либкнехт ур., 79 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89033135181);

Әҗем мәчете (Фәткуллин ур., 15 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89655876022);

Әл-Иман мәчете (Магистраль ур., 22 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89520312426);

Хузайфа мәчете (Ю.Фучик ур., 52 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89872285131);

"Аксу мәдрәсәсе (Әлмәт шәһ., Радищев ур., 12 нче а йорт, мөгаллимнең телефоны: 89172770363);

Казан нуры мәчете (Ф.Әмирхан ур., 3 нче йорт, 2 к., мөгаллимнең телефоны: 89274777500);

Ризван мәчете (Мәүлетов ур., 48 нче а йорт, мөгаллимнең телефоны: 89050206233);

Салихҗан мәчете (Бестужев ур., 26 нчы йорт, мөгаллимнең телефоны: 89033889439);

Нур Ислам мәчете (М.Бигиев ур., 36 нчы йорт, мөгаллимнең телефоны: 89033062591);

Җомга мәчете (Ильич ур., 4 нчы йорт, мөгаллимнең телефоны: 89870074579);

Мәрҗани мәчете (К.Насыйри ур., 17 нчы йорт, мөгаллимнең телефоны: 89063221059);

Әл-Иман мәчете – хатын-кызлар төркеме (Магистраль ур., 22 нчы йорт, мөгаллимнең телефоны: 89196449592);

Казан нуры мәчете – хатын-кызлар төркеме (Ф.Әмирхан ур., 3 нчы йорт, 2 к., мөгаллимнең телефоны: 89178831445);

Әтиләр мәчете – хатын-кызлар төркеме (Кояшлы бист., Күлбаш ур., 13 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 889274178158);

Ярдәм мәчете – хатын-кызлар төркеме (Серов ур., 4 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89047600545);

Тынычлык мәчете – хатын-кызлар төркеме (Яшел Үзән шәһ., Столичный ур., 8 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89274022910);

Шамил мәчете – хатын-кызлар төркеме (Ф.Әмирхан ур., 3 нче йорт, 1 к., мөгаллимнең телефоны: 89172972492);

Өметләләр мәчете – хатын-кызлар төркеме (2-нче Азин ур., 1нче в йорт, мөгаллимнең телефоны: 89274460985);

Гаилә мәчете – хатын-кызлар төркеме (Җ.Фәйзи ур., 3 нче йорт, мөгаллимнең телефоны: 89274146320).

# АНДА БАРМАУ МӨМКИН ТҮГЕЛ...

**Быел Гөлнара НӘБИУЛЛИНАга хәләл җефете белән бергәләп хаҗ кылу насыйп булды. Гөлнара - безнең хезмәттәшебез, Диния нәзарәтендә кадрлар бүлеген җитәкли. Кайтып җитеп, эшкә чыгуга аннан хаҗ хатирәләрен сөйләттек. Сөйләвен сөйләде, ә менә газетага бирик дигәч, риядан китәр дип курка калды, озак кына ризалашмый йөрде. Һәр гамәл ниятккә карап бәяләнә, укыган кешеләр файдасын күрсеннәр һәм күп гыйбрәтләр алсыннар, дип ул сөйләгәннәрне газетабызга бирергә булдык.**






***

Булачак ирем белән җитди очраша башлагач, бездә хаҗга барырга дигән теләк туган иде. Шушы ниятебезне сер итеп кенә әниемә дә әйтеп куйдым. Әмма гаилә коргач, ул никтер онытылды. Туй акчаларын җыештырып, Төркиягә барырга әзерләнеп йөргәндә, әни хаҗ турында исебезгә төшерде. Ә безнең ни паспортлар әзер түгел, ни никахыбыз загста теркәлмәгән. Җитмәсә, акчабыз да җитеп бетми. Икенче көнне иремә әйтмичә генә ДУМРТ ХАДЖга киттем. Анда, никахыгыз рәсмиләштерелмәгәч, без сезне ала алмыйбыз, диделәр. Чиратка язылып, бер ай көтеп торырга безнең вакыт юк. Ярдәм итә алмассыңмы, дип бер танышыма шалтыраттым һәм мәсьәлә бер көн эчендә хәл ителде. Әти-әниләр акча белән булыштылар. Әгәр ният итсәң, Аллаһы тәгаләгә тәвәккәл кылсаң акча җитмәү дә, башкасы да киртә була алмый икән. Ул "бул" дисә, була. Кеше гомере буе җыена, ә безгә 27 яшьтә хаҗ кылуны насыйп итте.

Изге сәфәргә икебез дә ныклап әзерләндек. Хаҗ оешмасы оештырган махсус дәресләргә йөрдек. Гыйбадәтләребезгә игътибарны арттырдык, яхшы гамәлләр кылырга тырыштык. Начар гамәлләр кылсак, Аллаһы Тәгалә юлны ничек ачкан булса - шулай ук ябып та куяр дип курыктык. Очкычта ләббәйкәне укый башлаганда, елыйсы килә, дулкынланасың икән, Җиддәгә төшкәч тә бик елаштык. Шунда ук Аллаһы тәгалә авырлыклар белән сыный да башлады. Күп сәгатьләр аэропортта булдык, эссе, юлда бөкеләр...

Беренче тапкыр таваф кылганда башымдагы бердәнбер уй - югалмасак кына ярар иде, булды. Бу гыйбадәтне мин икенче көнне генә бөтен күңелем белән башкара алдым. Йа, Раббым, син безгә менә нинди мөмкинчелек бирдең! Муллалар нәселеннән булган бер бабам, үз гомерендә өч тапкыр җыенып та хаҗга бара алмады. Башта акча җыйды, аннары квота белән нидер килеп чыкты, аннары сәламәтлеге ычкынгач: "Миңа хаҗ кылырга Аллаһ насыйп итмәгән, күрәсең", - диде.

Минем ирем кызурак кеше, аңа бар да тиз кирәк, күп кеше җыелган җирдә дә булырга яратмый. Хаҗда төрле җирдән җыелган, төрле менталитетлы миллионлаган кеше, мәчеттән 40-45 минут чыгабыз. Ә ирем тып-тыныч, әле, күресенчә, миңа "сабыр-сабыр" дип кенә тора. Без анда бер-беребезне башка яктан ачтык, Мәккә икебезне дә үзгәртте. Аллаһы тагәлә биргән һәр мизгелгә күбрәк шөкер итә башладык. Саусәламәт булып, үз динебезне тотып, бер-беребезне яратып, хөрмәт итеп яшәргә язсын, башка берни дә кирәкми. Ниятебез бозылмасын дип без хәтта базарга да йөрмәдек.

Изге урыннарда шайтаннар да бик көчле. Әни, калган намазларыңны шунда укырга тырыш, анда бер намазга әллә ничә мең намаз языла, дигән иде. Шулай итәргә телим, кинәт башыма "нәфел намазына барып тормыйча, бәлки таваф кылыргадыр", я булмаса "икендегә генә барыйк, бик эссе бит" дигән уйлар килеп керә. Кирәкмәгән уйларны куып, без гел гыйбадәттә булырга тырыштык.

Төрле хикмәтләрне дә, кылган догаларның шундук кабул булуын да күрдек без анда. Иремнен бүлмәдәш егете сөйләде, аның бер танышы таваф кылганда башмакларын югалткан. Шуларны таба алсам ярар иде, дип дога кыла икән бу. Беренче кат әйләнеп килгәч - бер башмагы, икенче тапкырында икенчесе аягына кереп кенә утырган. Менә шундый хикмәт! Ирем бик тә Кәгъбәгә кадәр барып җитәргә теләгән иде. Аллаһы тагәлә анысын да насыйп итте. Ул андагы җиңеллекне әйтеп-аңлатып бетерә алмады, тирәягында миллионнарча кеше, әмма беркем дә юк шикелле, ди.

Хаҗга әзерлек дәресләрендә Абдулла хәзрәт Галиев безгә: "Үзегез өчен генә түгел, туганнарыгыз, якыннарыгыз өчен дә дога кылыгыз, чөнки сезгә Аллаһы тәгалә шундый мөмкинлек биргән, ә аларга - юк", - дигән иде. Туганнарыбыз, дусларыбыз өчен дә бик озаклап - берәр сәгать догалар кылдык, Аллаһ кабул итсен, риядан китмәсен. Башта мин Раббыбыздан аларны дөрес юлга күндерүен, намазга бастыруын сорадым, чөнки фарыз намазыңны да укымаган кеше Аллаһы тәгаләдән нидер сорау дөрес түгел, минемчә. Кайвакыт: "Кәгъбәтуллада, Гарәфәттә догалар кабул була дигәннәр иде, кабул булмады менә", - дип аптыраучылар очрый. Ә алар кабул булсын өчен син нәрсә эшләдең соң?

.... Хаҗ - җиңел гыйбадәт түгел, без моңа әзер идек. Шулай да Минага баргач, җиңелчә шок кичердек. 200 кешелек чатырларда сиңа тиешлесе - матрас, мендәр дә юрган. Шунда ашыйсың эчәсең, йоклыйсың, намаз укыйсың. 60 градус эсселек, төрле холыклы кешеләр, кысан, бәдрәфләргә 40 ар минутлык чират, чөнки ничә миллион кеше бер җирдә бит. Сабыр, сабыр, тагын бер кат сабыр... Алты көн шундый шартларда яшәдек, хаҗның төп гамәлләрен үтәдек. Гарәфәт тавында хаҗилар утырып та, басып та, елый-елый да Аллаһы тәгаләгә ялвардылар - бу халәтне язып кына аңлата торган түгел.

Мөздәлифәгә килеп җиткәч, бер күренеш шаккатырды - актан киенгән миллионнарча кеше ком-таш өстендә йоклап ята, анда йоклап алу мәҗбүри. Хаҗ оешмасы бүләк иткән йокы капчыклары бик ярап куйды, шуларны җәеп асфальтка сузылып яттык. Бер-ике сәгать йоклаганбыздырмы, баш очыбызга килеп туктаган полиция машинасы тавышына уянып киттек, үтә алмыйлар икән. Намаз укырга да вакыт җиткән иде инде.

... Корбан бәйрәме көнне шактый күп йөрелде, ә кичен Мәккәгә саубуллашу тавафын кылырга барабыз, диделәр. Бүлмәдәшем - 81 яшьлек бер апа, аяклары бетте, бара алмыйм инде мин, ди. Без аны арбага утыртып таваф кылдырырга булдык. Автобуска барганда тагын бер апаның кан тамырларына көч килеп, анысын бер егет үз өстенә алды. Арба эзлибез, юк кына бит, тапсак ярар иде, дип дога кылабыз һәм менә ул- каршыбызда җыеп куелган килеш тора! Машалла! Безгә тагын бер арба кирәк бит әле. Кеше куплектән файдаланып, акча эшләргә тырышучылар да бар, бушка алган арбаны берәүләр 200 реалга арендага бирделәр. Ул көнне бик соң кайттык. Шунда бу изге җирләрдән аерылу ачысы җанны телгәләргә тотынды. Бөтен тәмен белеп гыйбадәт кыла башлагач кына...

Мәдинәгә кайткач, һәр намазга мәчеткә йөрдек. Анда бар да башкача: намаз вакытын зарыгып көтәсең, ләззәтләнеп тәһарәт аласың. Кеше күп, янәшәңдә кем генә утырмый, ничек кенә укымыйлар. Беркем беркемгә игътибар итми, бар да гыйбадәттә. Безнең мәчетләрдәге сыман, кызым, алай ярамый, болай кирәк, дип төрткәләүче юк. Пәйгамбәребез каберенә хатын-кызларны кичке 9 дан 12 гә кадәр кертәләр икән. Шунда ук җәннәт бакчасы дигән урын бар, аларын да күрдек. Пәйгамбәребез, Мәдинә кешеләр өчен имин шәһәр булсын, дип дога кылган. Ул, чыннан да, бик уңайлы шәһәр, кешеләр дә бик йомшак, ягымлы күренде.

Хаҗга бары тик ныклы иман белән генә барырга кирәк - мин әнә шундый фикер белән кайттым аннан. Иманың зәгыйфь булса, башыңа: "Нәрсә өчен Мөздәлифәгә барып таш өстендә йокладык инде без?", "Гарәфәттә нигә көне буе тору кирәк булды икән, гыйбадәтне берике сәгатьтә дә кылып бетерергә була иде бит", - дигән уйлар килергә мөмкин. Ә без: "Нигә?"- дип сорарга тиеш түгел, чөнки Пәйгамбәребез шулай эшләгән! Хаҗга яшь килеш, ирең, яисә мәхрәм кардәшең белән барырга кирәк, чөнки хатын-кызның үзенә генә бик авыр. Аллаһ һәркемгә шунда баруны насыйп итсен. Төркиясе, Гарәп Әмирлекләре - берсе дә кирәкми.

Хаҗдан кайткач, минем өчен туй сәяхәте дигән нәрсә бөтенләй кирәксезгә әйләнеп калды. Яңа өйләнешкән яшьләрне берни дә хаҗ кебек якынайта алмас. Холкыбызда да матур үзгәрешләр сизеп сөенәбез. Берәр ярамаганрак эш эшли, кирәкмәгән сүз сөйли башласак, әйдә, хаҗыбызны бозмыйк әле, дип бер-беребезне туктатабыз. Кайткач, ике атна буе хаҗ төшебезгә керде. Күңелдәге сагышны әйтеп-аңлатып булмый, әйтерсең лә монда берни дә үзеңнеке түгел, синеке әнә анда калган. Ул җирләрдә бернинди хәвефләнү, бернәрсәдән курку юк. Ә эчкән суыңның, йоклаган йокыңның, тоткан акчаның бәрәкәтен әйтеп бетерә торган түгел. Кайбер нәрсәләргә карашлар үзгәрде. Элек, менә фәлән кеше ике елдан соң тагын хаҗ кылырга киткән икән, дисәләр, минем ачуым килә, акчасы бар икән, бер дә бармаган кешеләргә бирсен әнә, дия идем. Хәзер алай димим. Күңел шулкадәрле тарта - мөмкинлегең булса, анда бармау мөмкин түгел.

# "ӨМЕТ"ЛЕ КИЛӘЧӘК



**Әмәт бистәсендә күптән көтелгән "Өмет" мәчете эшли башлады. Күптән көтелгән дим, чөнки мәхәлләсе байтак еллар элек оешса да, мәчет төзү һаман тоткарланып килде. Мәчетнең имам-хатыйбы Равил хәзрәт Бикбаев исә, гасырлар буе көтелгән, дигән фикердә. "Үзем туктаган чыганакларга караганда, Явыз Иван Казанны алган вакытта бу урында Әхмәт байның җирләре булган. "Әмәт" "Әхмәт"тән алынган булса кирәк, чөнки татарлар элек Әхмәтне – Әмәт, Мөхәммәтне – Мәмәт дип кыскартып әйтә торган булганнар бит. Шуннан соң инде бу җирдә татарның әсәре дә калмый, кирәк вакытта мулланы да читтән китертәләр. Казанның тарихи урынында бу – безнең беренче мәчетебез", – ди хәзрәт.**

Мәхәлләнең оешуы 90 нчы еллар ахырына туры килә, бистә активистлары - Дания, Тәскирә абыстайлар, өйдән-өйгә йөреп, мәчет төзелеше өчен акча җыя башлый. Әмәт бистәсенең ул вакыттагы җитәкчесе Альберт Сәяхов тырышлыгы белән 2005 елда төзелешкә җир бүлеп бирелә. Монда башта йортлар булган, безнең нигез, дип әле дә корбан чалырга килүчеләр бар икән. Берничә ел машина кую урыны вазифасын үтәгәннән соң, Аллаһның рәхмәте белән, әлеге 21 сутый җир кишәрлеген мәчеткә бирәләр. Бик зур мәчет проекты төзелә, документация эшләнә. Мәхәллә имамы итеп Рәшит хәзрәт Хәмидуллин сайлана. Аннан соң 2009 елда бу вазифаны Рөстәм хәзрәт Әхмәтшин дәвам итә. Шул ук елны нигез чокыры казыла, ләкин акча булмау сәбәпле төзелеш туктап кала.

2011 елны мәхәллә халкы Мәккәдәге Уммуль-Кура университетында гыйлем алган Равил хәзрәт Бикбаевны имам-хатыйб итеп сайлап куя. Күпләр Равил хәзрәтне үтемле вәгазьләре аша белә. Имамлык вазифасы өстенә ул әле Милли китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә дә эшли, "Хузур" нәшрият йортында актив эшчәнлек алып бара.

- Ул проектны тормышка ашыру өчен бик күп акча кирәк иде, - дип сөйли Равил хәзрәт. - Мәхәлләдәге актив картлар, әбиләр белән киңәшләшкәндә алар да: "Безгә зур мәчет булмаса да ярый, әмма затлы булсын, кирпечтән булсын, янәшәдән тимер юл уза бит - читтән балкып күренеп торсын", - дигән теләкләрен белдерделәр. Шулай итеп, проектны бераз үзгәртергә туры килде, 2012 елның җәендә төзелешне башлап җибәрдек. Бер ел эчендә нигезен, диварларын күтәрдек, кыш көне түбәсен яптык. Намаз уку заллары, керү юллары әзер, инде хәзер - аскы катта уку бүлмәләрен, таһәрәтханәне эшләп бетерәсе, ишегалларын тәртипкә саласы бар. Мәхәллә халкы, Диния нәзарәте һәм иганәчеләребез ярдәменнән башка, әлбәттә, бу эшләрне башкарып чыгу һич мөмкин түгел иде. "Винербергер" оешмасы бушка кирпеч бирде, "Кулонстрой"-ның да ярдәме зур булды.

Мәчет әлегә рәсми төстә ачылмаса да эшли башлаган инде. Узган елның 3 августында тантаналы төстә манарасына ай куелып, беренче тапкыр өйлә намазы укылган. Хәзерге көндә җомга намазына 100 әр кеше җыела икән. Узган елдан башлап Гает намазларын да биредә укыганнар. Коръән түгәрәгендә унлап бала йөри (өчесе - имам-хатыйбның үзенекеләр), абыстайлар дәрес бирә.

Мәчет калкулыгыннан метро станциясенә төшкәндә, тагын бер кат артка борылып карадым да, чыннан да, хыяллары тормышка ашкан бит Әмәт әбиләренең, дип уйлап куйдым. Мәчетләре җыйнак кына, әмма затлы булып, ерактан балкып тора. Күркәм эшчәнлеге белән дә бөтен Казаныбызда балкырга насыйп булса иде.

***Мәрьямбану ХАФИЗ***











# ТАУ КУЫШЫНДА КАЛГАН ӨЧ ЮЛЧЫ

*Гомәрнең улы Габдуллаһ риваять иткән, көннәрдән бер көнне пәйгамбәребез саллаллаһу гәләйһи үә сәлләм тау куышында калган өч юлчы турындагы кыйссаны сөйләгән: "Сезгә кадәр яшәгән өч кеше сәфәргә чыкты. Төнне шунда үткәреп, юлларын көндез дәвам итү нияте белән алар бер тау куышына керде. Тыныч кына йоклап ятканда тау башыннан зур гына таш тәгәрәп төште һәм тау куышыннан чыга торган юлны каплап куйды. Әлеге гаҗәп хәлнең шаһитлары булган юлдашлар, бер-берсенә карашып: "Безне моннан башка берәү дә түгел, бары тик, изгелекләребезне искә төшереп, Аллаһыга мөрәҗәгать итүебез генә коткара алачак", - диеште. Шуннан соң, аларның берсе эшләгән изгелеген искә төшереп: "Әй Аллаһым, минем олы яшьтәге әтием һәм әнием бар иде. Кадерле кешеләремә зур хөрмәт күрсәтеп, һәр көнне кич белән яңа гына сауган сөтне иң элек аларга эчертә идем. Шулай итеп, көннәрнең берсендә утын җыярга барган идем, шул сәбәпле өйгә соңгарак калып кайтырга туры килде. Яңа гына савылган сөтне кулыма тотып, әти-әнием янына бүлмәгә кердем һәм аларның йоклап киткәннәрен күрдем. Аларны уятып борчырга теләмәдем һәм: "Бәлки уянырлар", - дип, таңга кадәр сөт салынган савытны кулымда тотып басып тордым. Балаларым, иртән уянып: "Әти, безгә сөт бир әле", - дисә дә, әти-әнием уянса аларга эчертермен дип, сөтне балаларыма бирмәдем. Әй Раббым - Аллаһым, бу эшемне Синең ризалыгың өчен эшләгән булсам, шуның хакына безне бу тау куышыннан коткар", - диде. Шуннан соң, таш беразкузгалды, әмма пәйда булган ул тишек куыш эчендә калганнар чыга алырлык түгел иде. Юлчыларның икенчесе дә, үзенең изгелеген искә төшереп: "Әй Аллаһым, мин дә бер кызны бик яратып, сөеп йөргән идем, тик ул әтинең абыйсының кызы иде. Мин аның белән якынлык кылырга теләгәч, ул бу эшкә ризалык бирмәде, ягъни зина гөнаһына кермәде. Көннәрнең берсендә ул кыз миннән ярдәм сорап килде. Мин аңарга йөз егерме алтын акча бирдем һәм шуның өчен минем белән зина кылуын үтендем. Ул исә ризалык белдерсә дә, бу эшне эшләр алдыннан миңа: "Аллаһыдан курык, бу эшне эшли күрмә", - диде. Шушы сүзләрдән соң, ул кызны мин шулкадәр яратсам да, зина кылудан тыелып калдым һәм аңа биргән акчаның бер тиенен дә кире кайтарып алмадым. Әй Аллаһым, әгәр дә мин бу эшемне, ягъни*



*гөнаһ гамәлдән тыелып калуымны, Синең ризалыгың өчен эшләгән булсам, безне бу тау куышыннан коткар", - диде. Әлеге үтенечтән соң таш тагын беразгына урыныннан кузгалды, әмма куыш эчендә әсирлектә калганнар аннан барыбер чыга алмады.*

*Юлчының өченчесе, үзенең кылган игелеге хакында сүз башлап, болай диде: "Мин берничә кешене эшкә яллаган идем. Эшләрен кимчелексез, сыйфатлы итеп башкарганнары өчен үзләренә тиешле хезмәт хакларын түләдем. Берсеннән тыш, барысы да хезмәт хакларын алды. Ул исә: "Соңрак килеп алырмын", - диде. Тик берничә елдан соң гына килде. Мин аңа: "Бу дөяләр, сыерлар, сарыклар - барысы да синеке, алып кит аларны", - дигәч, ул бик тә гаҗәпләнеп: "Ник мине мыскыл итәсең, син бит миңа башкарган хезмәтем өчен бу кадәр бирергә тиеш түгелсең", - диде. Мин аңарга: "Синең алып китмичә калдырган малыңны бер урында саклап тормадым, үрчеттем һәм ишәйттем", - дидем. Ул мин тапшырган малның, берсен дә калдырмыйча, барысын да алып китте. Әй Аллаһым, мин бу эшне Синең ризалыгың өчен башкарган булсам, безгә ярдәм ит", - дип ялварды. Әлеге ихлас сүзләрдән соң, тау куышы тишеген каплаган таш бөтенләй кузгалды һәм юлдашлар, исән-имин яктылыкка чыгып, сәфәрләрен алга таба дәвам итте" (Бохари, Мөслим).*

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Әлбәттә, пәйгамбәребез саллаллаһу гәләйһи үә сәлләм сөйләп калдырган бу кыйссада бик күп сабаклар бар. Без исә шуларның берничәсен генә искә төшереп китик.

1. Бу кыйссада пәйгамбәребез саллаллаһу гәләйһи үә сәлләмнең "өч кеше сәфәргә чыктылар" дигән сүзенә тукталып китәсе килә. Чыннан да, шушы өч кеше кебек без барыбыз да гомеребезне дөнья сәфәрендә үткәрәбез. Ә инде сәфәргә килгәндә ул җиңел булмый, ягъни бу фаный дөньяда яшәгәндә Аллаһы тәгалә безне төрлечә сыный. Авырлыгын да бирә, рәхәтлеккә дә юлыктыра һәм шушы сынаулар аша кеше үзенең кем икәнен раслый, ягъни сынау сәфәрен үткәндә, кемдер иманлы, кешелекле һәм күркәм әхлаклы булып кала. Ә инде кайберәүләр эчке матурлыгын югалта, әхлакый яктан караганда, хайваннардан да түбәнрәк дәрәҗәгә төшә. Шуңа күрә иң мөһиме - дөнья сәфәрендә нык ихтыяр көчле, сабыр булу кирәк. Иңнәребезгә нинди генә авырлыклар төшсә дә, тормышның нинди сынаулы мизгелләре булса да, төшенкелеккә бирелмичә, өметне өзми һәрчак алга таба омтылып яшәргә кирәк.

2. Төнне шунда үткәреп, юлларын көндез дәвам итү нияте белән алар бер тау куышына керделәр. Бу сүздән нинди гыйбрәт алып була дигәндә, җавап шундый: акыллы адәм баласы яшәр өчен көнен дә, төнен дә тынычлыкта үткәрер өчен тыныч һәм бәрәкәтле урын эзләргә тиеш. Аеруча, гаилә иминлеген кайгыртып, сугышларсыз, фетнәсез тыныч урын эзләү һәрбер гаилә хуҗасының иң зур бурычы.

3. Тыныч кына йоклап яткан вакытта тау башыннан зур гына таш тәгәрәп төште һәм тау куышыннан чыга торган юлны каплап куйды. Бу сүзләрдән түбәндәгеләр аңлашыла: никадәр иминлектә яшәсәк тә, безгә бернәрсә дә кагыла алмас, без сакчылык астында көчле, куәтле, абруйлы, дәрәҗәле кешеләр, дип масаю һәм, Аллаһы сакласын, тәкәбберләнү ярамый, чөнки кодрәт иясе булган Аллаһы тәгалә тәкәбберләнүчеләрне сөйми һәм Аның рәхмәтенә яисә ачуына беркем дә һәм бернәрсә дә киртә була алмый.

4. Әлеге гаҗәп хәлнең шаһитлары булган юлдашлар берберсенә карашып: "Безне моннан башка берәү дә түгел, бары тик, игелекләребезне искә төшереп, Аллаһыга мөрәҗәгать итүебез генә коткара алачак", - диештеләр. Әйе, чыннан да, адәм баласы башына берәр авырлык төшсә, ул иң беренче ярдәмне читтән эзли башлый, ягъни туганнарына, дусларына мөрәҗәгать итеп карый. Беркаян да ярдәм таба алмагач кына Аллаһы тәгаләгә ялварырга тотына. Тик кайбер очракларда соң була инде, җәза буларак, Аллаһыдан да җавап килми. Кеше никтер бернәрсәне аңлап бетерми: туганнарыбыз яки дусларыбызның безгә ярдәм итә алулары да Аллаһының ярдәме һәм рөхсәте белән генә ирешә. Шуңа күрә, безгә нинди генә авырлык килсә дә, иң беренче итеп ихлас күңелдән Аллаһы тәгаләдән ярдәм сорыйк, Аңарга ялварыйк. Бары тик шуннан соң гына, сәбәпләрен эзләп, танышларыбызга мөрәҗәгать итик. Шулай эшләсәк, иншаллаһ, омтылган нәтиҗәгә ирешербез, ачык ярдәмне үз күзебез белән күрербез. Әмма, тагын шунысын да искәртеп үтүне кирәк дип саныйм: Аллаһы тәгалә безнең ялваруларыбызга җавап бирсен өчен без дә, Аның ризалыгын өмет итеп, эчкерсез, ихлас изгелекләр кылырга тиешбез. Чын йөрәктән эшләгән изгелек беркайчан да нәтиҗәсез калмый. Ул кешенең үзенә ярдәм яки шатлык-куаныч булып әйләнеп кайта. Шуңа күрә, бу дөньялыкта да, ахирәттә дә отучылардан булырга теләсәк, изгелек орлыкларын күбрәк чәчсәк иде.

> ***Изгелекне Аллаһ ризалыгы өчен эчкерсез эшләнгәндә генә аның уңай нәтиҗәсе булачак. "Фәләннең файдасы тияр" яки "Миңа рәхмәт әйтсеннәр, мактасыннар", дип эшләнгән изгелекләр берничек тә эчкерсез була алмый. Черегән орлык үсеп җимеш бирмәгән кебек, эчкерле изгелекләр дә татлы җимеш бирмиячәк.***

5. Югарыда сөйләнгән кыйссадагы юлчылар кылган изгелекләрен искә төшереп, шулар хакына, хөрмәткә һәм яклауга өметләнеп, Аллаһыга мөрәҗәгать итәләр. Шуңа күрә, дога кылыр алдыннан эшләгән изгелекләрне искә төшереп, шулар хөрмәтенә дип теләк теләү күркәм гамәл санала һәм, әлбәттә, алар доганың кабул булуына сәбәп булачак.

6. Өч юлчы да изгелекләрен сөйләп күрсәткәч: "Әй Раббым - Аллаһым, бу эшемне Синең ризалыгың өчен эшләгән булсам, шуның хакына безне тау куышыннан коткар", - диләр. Әлеге сүзләреннән соң "нигәдер изгелекләрнең нәтиҗәсен күрмим?" диючеләргә ачык җавап: изгелекне Аллаһ ризалыгы өчен эчкерсез эшләнгәндә генә аның уңай нәтиҗәсе булачак. "Фәләннең файдасы тияр" яки "Миңа рәхмәт әйтсеннәр, мактасыннар", дип эшләнгән изгелекләр берничек тә эчкерсез була алмый. Черегән орлык үсеп җимеш бирмәгән кебек, эчкерле изгелекләр дә татлы җимеш бирмиячәк.

7. Югарыда сөйләнгән кыйссада өч төрле изгелек турында сүз бара. Изгелекләр алар бик күп төрле, барысын да санап бетереп тә булмый. Гади генә елмаюдан башлап, кешене үлемнән коткарып калуга кадәр, хаҗга барып кайтудан алып, юлда хәлсезләнеп яткан эткә су эчерүгә кадәр - барысы да изгелек. Әмма ләкин, шуңа да карамастан, бу кыйссада өч төрле игелек искә алына: беренчесе - ата-анага карата булган игелек, икенчесе - зинадан тыелу, өченчесе - сакчылыкка калдырган әманәтне иң күркәм рәвештә саклау. Изгелекне хаҗга барып намаз укуда, ураза тотуда дип кузаллаган кешеләргә бу кыйссаны игътибар белән берничә тапкыр укырга кирәк. Дин кешеләрне бер-берсенә карата яхшы күркәм мөгамәләдә булырга өйрәтә, һәм асылда, диннең максаты да шуннан гыйбарәт. Тау куышында калган юлчылар да, шикләнмим, намазын да укыганнардыр, бәлки, хаҗга да барганнардыр, ләкин кылган изгелекләрен искә төшергәндә, намаз укыганым хөрмәтенә, хаҗга бару хакына дип дога кылмадылар, чөнки асылда Аллаһы каршында югары бәя күркәм мөгамәлә өчен бирелә.

8. Хөрмәтле мөселманнар! Гыйбрәтләрнең сигезенче буларак, шуны әйтеп китик. Нинди генә авыр хәлдә булсак та, шуны белик: гәмәл капчыгыбыз йөрәгебездә Аллаһыга карата мәхәббәтебез һәм эчкерсез изгелекләр белән тулы булсын. Ач калсак, ризык безне үзе табар, каршыбызда бикләнгән бәрәкәт ишекләре сәбәпсез ачылырлар, караңгы төннәребез яктырыр, кояшлы көнгә болыт безнең күләгәбез булыр, дога кылыр өчен кулларыбызны күтәрер алдыннан ук Аллаһы теләкләребезне кабул итәр.

***Вәгазьне***
***Казан шәһәре казые***
***Мөхмүд хәзрәт***
***ШӘРӘФЕТДИН әзерләде***

# ҖӘННӘТ КҮБӘЛӘКЛӘРЕННӘН БАШ ТАРТМАГЫЗ!

**Җиһанга бар көченә аваз салып, сабыем туды. Тупырдап торган улымны күргәч, йөрәк түрендәге әле моңарчы сиздермәгән "яңа нокта" "дөп"елдәп куйды. Үземне ана итеп сизү тойгысы иде ул. Әйтерсең, бала тудыру йорты тәрәзәсе артында барган мәшәкатьле, шау-шулы тормыш бер мәлгә туктап калды, бөтен игътибарым шушы кечкенә генә җанга күчте дә куйды. Бу хисне - ана булу хисен тату никадәр бөек, рәхәт, ләззәтле икән.**

Ак биләүгә биләгән сабыем белән, яңа куанычлы мәшәкатьләр өстәп, өйгә кайттык. Кырык яктан кырык сорау килде дә басты алга. Янымда бөтерелеп йөрердәй әнием белән кайнанам юк, ирем миннән дә тәҗрибәсезрәк. Әле ярый телефон заманы, әнкәй үзенең бар белгәнен шуннан әйтеп тора. Дөрес, бер-ике атна элек өйгә шәфкать туташы килеп, кәгазь тутырып китте-китүен. Шуннан соң күренгәне юк әле.

Әй, элгәре бишәр баланы ничек үстергәннәрдер, бишек янында ирем белән икәүләп бөтерелеп тә җитешеп булмый. Төнгелеккә "памперс" дигәне ярдәмгә килсә, көндез юыну бүлмәсеннән чыгып булмый... Зарлануым түгел бу, юк. Киресенчә, баланың кадере шушы борчу-мәшәкатьләре, һәр көнне күзгә күренеп үсүе, күрсәткән кечкенә "һөнәрләре" белән арта гына бара икән. Ләкин, кызганыч, бар анага да моны аңлау бирелмәгән шул...

Бала тудыру йортында сабыйларыбызны беренче тапкыр имезергә алып килгәч, бүлмәдәш хатын: "Юк! Имезмим дә, тотмыйм да, күрәсем дә килми", - дип, баласыннан баш тартты. Менә шунда миңа, үзе дә балалыктан чыгып кына килүче яшь анага, тормыш яңа ягы белән ачылды. Ачы ягы белән...

Тәүге тапкыр әнисен күрергә, аның исен сизәргә, аңа дип төшкән сөтне туйганчы ашарга килгән нарасый нәүмиз калып, ярты юлда кире борылды... Анасына үпкә белән елаган тавышы гына коридор буйлап яңгырап калды... Үз сабыйларыбызны да имезергә кирәк икәнлекне онытрык шул вакытта. Бүлмәдәге бала тоткан һәр ананың күзендә яшь. Һәркемгә чит, оят булып китте. Әйе, мин оялдым, шул нарасый алдында үземне нигәдер гаепле тойдым. Әйтерсең, ул елау аша баласын кочаклаган һәр анага: "Мин синең балаңнан киммени? Без бит бер көндә тудык. Мин дә әни кочагында иркәләнер, бәхетле булыр өчен тудым. Нигә мине яратмыйлар, чит күрәләр?" - дия төсле. Үз сабыема караган саен читенсенүем арта гына. Ул зарыгып көтеп алынган, кирәкле, кадерле... Ә теге нарасый - артык, кирәксез, чүп... Бер төндә, бер бүлмәдә дөньяга килгән ике сәламәт баланы ике төрле тормыш көтә. Берсен - бәхетле, тулы гаилә, икенчесен - балалар йортының шыксыз ятимлеге...

Җитлекмичә туган баласы өчен ут йотып йөрүче, көнентөнен Аллаһка ялварып утырган бер хатын: "Аллаһ сиңа шундый зур бәхет, нигъмәт - сәламәт бала биргән, ничек син Аллаһның бүләгеннән баш тарта аласың? Ә башка мондый бүләк ясамаса? Үкенерсең, соң түгел әле, кире уйла!" - дип, басым ясарга, үгетләргә тырышса да, "ана" кеше бирешә торган булмады: үзен нык, горур тотты. "Кияүдә түгелмен әле, бала белән мине кем алсын?! Яшәр җирем дә юк, кеше өстендә генә торам! Кызганыч булса, үзеңә тәрбиягә ал!" - дип кенә кычкырды ул.

Бала табу йортыннан бергә чыктык без аның белән. Мине гаиләм, туганнарым, шау-гөр килеп, чәчәк бәйләмнәре белән каршы алганда, ул башын горур тотып, ялгыз ишеккә юнәлде. Мин кыенлыкларга бирешмәдем, мин көчле, имеш. Әйе, ул көчле. Ничә айлар буе карынында тибенгән нарасыйдан баш тартыр өчен, чынлап та, зур көч кирәк. Ләкин ул көч аңа күңел тынычлыгы, бәхет китерерме соң? Ялгыз гына чыгып китүен күргәч, аңа булган нәфрәтем юкка чыкты. Юк, ул баланы ятим итмәде, ул баласы - үзе ятим...

Кызык инде бу дөнья. Берәүләр инвалид бала тәрбия кылганда, икенчеләр баласызлыктан интегеп утырганда, өченчеләр җиңел генә газиз сабыйларыннан: "Юк!" - дип баш тарталар. Аллаһы тәгаләнең гыйбрәтеме, әллә җибәргән сынауларымы... Ни генә булмасын, ләкин бөек Аллаһ сине зурлап, сиңа ышанып тапшырган баланы читкә кагу ялгышлыкларның иң олысыдыр, мөгаен. Ә гөнаһы күпме! Аллаһы тәгалә Коръәндә: "Байлык һәм балалар - бу дөньяның зиннәтләре...", - дип әйткән ("Кәһеф" сүрәсе). Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) дә: "Балалар - җәннәт күбәләкләре алар", - дигән сүзләре бар. Аллаһ зиннәт саnаган, рәсүлебез җәннәт күбәләге итеп күргән баланы гади кешенең чүп урынына күрергә ни хакы бар? "Әзер түгелмен", "ирем юк", "финанс ягым чамалы" ише гаепләр табып, күпме генә акланырга тырышсаң да, Аллаһ каршында бу акланулар белән котылырмын димә. Бала үз ризыгы белән туа, диләр. Баласына карата кадерхөрмәт күрсәткән ата-анага Аллаһ үзе үк ярдәм итә бит...

Бу уйларымнан балам айнытып җибәрде. Әнә асты юешкә борсалана ук башлады. "Ий, җәннәт күбәләгем, бәхетләрең генә була күрсен..."



*Мәрьям АБДУЛЛИНА,*
*КФУ студенты*

## СОРАУ-ҖАВАП

**- Иҗәб - кабул кылынганнарга (ярәшелгәннәргә) телефоннан сөйләшү яисә смслар аша аралашу рөхсәтителәме?**

- Мөселманнарның бер-берсе белән виртуаль яки ниндидер башка ысул белән аралашулары яхшы сыйфат булып тора. Ләкин бу бер җенес вәкилләренә генә кагыла, ягъни кызларга - кызлар белән, ир-атларга ир-атлар белән генә аралашу рөхсәт ителә.

Иҗәб никахка керү булып тормый, бары өйләнешергә ниятләре булулары турында сүз бирешү генә. Нәкъ менә шуңа күрә дә никахка кергәнгә кадәр ярәшелгәннәр бер-берләренә чит кеше булып тора, аларның бер-берсе белән аралашулары мәхрәм катнашында гына булырга тиеш. Ярәшелгәннәр берберсе белән очрашуга да якын туганнарының берсе белән генә барырга тиеш. Әгәр очрашулар вакытында шәригать хөкемнәре үтәлмәсә, бу бернинди дә яхшылыкка китермәячәк. Иҗәб - шәригать күзлегеннән караганда, ир-ат белән хатын-кызның ирекле аралашуы рөхсәт ителүнең бер шарты булып тора алмый.

## ГАИЛӘ КАКШАУНЫҢ 10 СӘБӘБЕ

**Экспертларның күзәтүләре буенча, иң уңышлы саналган мөселман гаиләләрендә дә проблемалар була икән. Нинди проблемалар соң алар? Икең дә теләгәндә, аларны хәл итеп буламы? Бу язманы укыганнан соң, бәлки, гаиләдәге үзара мөнәсәбәтегезгә башка яктан карарсыз, файдасы булмый калмас, дигән өмет белән экспертларның күзәткәннәрен сезгә дә җиткерергә булдык.**

1. Ирегезне яки хатыныгызны үзгәртергә тырышу. Шуны аңларга кирәк: әгәр, мәсәлән, шапшак иргә кияүгә чыккансыз икән, сез теләгәннән генә ул шундук пөхтә кешегә әверелмәячәк. Монда үзгәртеп була торган бердәнбер нәрсә - бу хәлгә үзегезнең мөнәсәбәтегез.

2 . Сөйләшү - аралашу түгел, тыңлау - ишетү түгел. Җәмәгатегезнең фикеренә колак салмыйча, үз фикер-теләкләрегезне, ризасызлыгыгызны гына белдерү - аралашуга керми. Үз фикерегезне тәнкыйтьләмичә, үпкәләмичә әйтергә өйрәнегез. Бер-берегезнең фикерен ишетергә, аңларга тырышыгыз.

3 . Вакытыгызны дөрес бүлегез. Хәзерге тормыш бик киеренке, шуңа күрә вакытны дөрес файдаланырга өйрәнергә кирәк. Хәзерге яшь парлар, замана артыннан куып, бар нәрсәгә дә өлгерергә тырышып, бер-берсе турында, гаилә турында онытып җибәрә. Аеруча замана технологияләре - телефоннан сөйләшүләр, интернетта утырулар да ир белән хатын мөнәсәбәтләренә зур зыян сала.

4. Интим мөнәсәбәтләрнең булмавы - мөселман гаиләсендәге зур проблемаларның берсе. Сүз җенси якынлык турында гына бармый, бу аның бер өлеше генә. Ир белән хатын рухи, акыл, физик, хисси яктан бер-берсенә бәйләнгән булса гына бу гаилә тотрыклы санала.

5. Игътибарның кимүе. Балалар тугач, ир кеше үзенә хатынының игътибары кимегәнен сизәргә, гаиләдә үзен кирәксез дип тоя башларга һәм игътибарны читтән эзләргә мөмкин.

6. Акча җитмәү. Экспертлар фикеренчә, акчаның җитмәве ир белән хатын мөнәсәбәтләренә хыянәткә караганда да зуррак зыян сала. Ир дә, хатын да эшли торган гаиләләрдә еш кына керемнәрнең тигез булмавы аркасында үпкәләш- аңлашылмаучанлыклар килеп чыга.

7 . Кичерергә өйрәнегез. Җәмәгатеңне юк кына нәрсә өчен дә гафу итмәү зур проблемалар китереп чыгарырга мөмкин.

8. Бер-береңне бәйләп бетермәү дә үпкәләш-талашка, хәтта хыянәткә китерергә мөмкин. Ир һәм хатын бер-берсен ничек бар - шулай кабул итәргә тиеш.

9. Еш кына яшьләр үзләренең хис-кичерешләрен тормыш иптәше белән түгел, ә социаль челтәрдәге танышлары белән бүлешә. Ә бит нәкъ менә хисләреңне бүлешү, фикер уртаклашу кешеләрне берләштерә, мөнәсәбәтләрне ныгыта.

10. Хакимлек итү өчен көрәш. Ир белән хатын бер-берсен уздырырга тырышканда алар өчен җиңү үзара мөнәсәбәтләрдән мөһимрәк булып тоела башлый. Бу исә гаилә тормышының җимерелүенә китерергә мөмкин.

*Сәхифәдә ISLAM-TODAY язмалары файдаланылды*

# "ҺӘР ТАВЫККА "БИСМИЛЛӘ – АЛЛАҺУ ӘКБӘР" ӘЙТЕЛЕРГӘ ТИЕШ"

**Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ, хөрмәтле "Азан" интернет-радиосын тыңлаучылар. Бүгенге тапшыруыбызның кунаклары – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарт комитеты рәисе Марат НИЗАМОВ һәм комитетның шәригать бүлеге белгече Илгиз БАҺАУТДИНОВ**




**Алмаз ӘХМӘТҖАНОВ:** - Әйдәгез, әңгәмәбезне: "Нәрсә ул хәләл?" - дигән сораудан башлыйк әле.

**М.Н.:** - Бу сүз гарәп теленнән "рөхсәт ителгән" дип тәрҗемә ителә, һәм ул азык-төлеккә генә түгел, тормышыбызның барлык өлкәсенә дә карый.

**И.Б.:** - Беренчедән, рөхсәт ителгән һәм тыелган турында Аллаһы сүбхәәнәһү үә тәгалә Изге Коръәндә әйтә. "Бәкара" сүрәсендә, үләксә, кан, дуңгыз ите һәм Аллаһ исемен әйтмичә суелган терлекләрнең итен ашау тыела, диелгән. Шулай ук ерткыч хайваннар, кимерүчеләр, ерткыч кошлар ите, бөҗәкләр дә хәрам санала. Кошинель дигән бөҗәкне аерып әйтәсем килә, аннан азыкка кызыл төс бирә торган Е120 азык өстәмәсе ясыйлар.

**А.Ә.:** - Кайбер гарәп илләрендә саранча ашыйлар. Сез моңа ничек карыйсыз?

**И. Б.:** - Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрендә саранчаны ашарга рөхсәт ителүен әйтә. Аллаһы тәгалә "Бәкара" сүрәсенең 172 нче аятендә: "Ий, мөэминнәр! Без сезгә биргән пакь, хәләл ризыкларны гына ашагыз..." диелгән. Димәк, бары тик чиста ризык кына кулланырга тиешбез, беренчедән, ул кешенең организмына зыян салмый, икенчедән, кешенең табигатенә килешә, ягъни күңеле тартып ашый.

**А.Ә.:** - Иткә килгәндә, дуңгыз итеннән кала тагын нинди терлек итен куллану тыела?

**И.Б.:** - Мул һәм ишәк ите, шулай ук бака, крокодил ите дә хәрам.

**А.Ә.:** - Ә крокодил тиресе белән нишләргә?

**И.Б.:** - Моңа ислам галимнәренең җаваплары шундый: дуңгыз тиресеннән кала барлык төр тиреләр дә эшкәрткәннән соң чистара.

**А.Ә.:** - Бик күпләрне тагын шундый сорау кызыксындыра, әгәр сыер хәләл түгел икән, аның сөтен эчәргә ярыймы?

**И.Б.:** - Ите рөхсәт ителгән малларның сөтләре дә хәләл, һәм, киресенчә, итләре хәләл булмаган терлекләрдән җитештерелгән азык-төлек, ягъни сөт хәләл түгел.

**А.Ә.:** - Гади авыл кешесе, фермер терлекне суйганда нинди кагыйдәләрне үтәргә тиеш?

**И.Б.:** - Беренчедән, терлек - хәләл, икенчедән, ул сәламәт булырга тиеш, өченчедән, терлекне чала торган кешенең мөселман, ягъни Изге китапларга ышана торган кеше булуы мәҗбүри. Малны суйганда, "Бисмиллә - Аллаһу әкбәр" дип әйтеп, (терлек каршында кайралмаган) үткен пычак белән үңәчен һәм муен кан тамырларын кисеп җибәрәләр. Бу очракта бөтен санитария-гигиена кагыйдәләре, шәригать таләпләре үтәлергә тиеш, әгәр пычрак, нәҗес эләксә, бу ит хәләлдән хәрамга әйләнергә мөмкин.

**А.Ә.:** - Ә механик юл белән суелган терлек ите хәләл буламы?

**И.Б.:** - Бүгенге көндә күп кенә галимнәр, терлекне механик юл белән чалу тыела, дигән фикердә. Хәтта предприятиеләрдә дә һәр тавыкка аерым "бисмиллә - Аллаһу әкбәр"не әйтеп, бары тик кулдан гына суярга тиешләр.

**М.Н.:** - Шуны әйтергә кирәк, 2009 елда техник регламент һәм метрологиянең Федераль агентлыгында теркәлгән "Хәләл" сертификацияләү системасы буенча малны кулдан чалу каралган.

**И.Б.:** - Әйтеп үткәнебезчә, суйганда терлекнең үңәче һәм муен кан тамырлары киселә, ә механик ысул белән башкарганда бу шарт үтәлеп тә бетмәскә мөмкин. Терлекнең авырлыгы, муен озынлыгы төрлечә булып, пычак тиешле урынга туры килмичә, башка өлешләренә зыян китерүе бар.

**А.Ә.:** - Сез әйтеп үткән азык-төлек өстәмәләренә әйләнеп кайтасым килә. Нәрсә ул Е өстәмәләре һәм аларның барысы да тыелганмы?

**М.Н.:** - Аларның исәбе хәзер 1500 меңгә җиткән! Е өстәмәләрне азык-төлекнең саклану вакытын озайту өчен кулланалар. Җитештерүче үз товарын сату өчен тырыша, белүегезчә, саклау вакытлары төрле. Ул әле товарының үзкыйммәте арзан булуын да кайгырта, ә шундый өстәмәләр табигый продуктларны алыштыра. Болардан тыш алар дымлылыкны саклый, җитештерүче ризыкның тышкы кыяфәтенең матур булуын да кайгырта бит әле. Кызганычка, табыш артыннан, күбрәк товар сату артыннан куып, шәригать рөхсәт итмәгән, кеше организмына зарарлы әнә шундый өстәмәләр кулланалар. Өстәмәләрнең кайбер төрләренә тукталсак, аларның бөҗәкләрдән ясалганы, составында алкоголь, хәрам саналган терлек майлары булганнары, озак вакытлар дәвамында кулланганда организмга зарар сала торганнары бар. Гап-гади желатинны гына алыйк, бүгенге көндә ул нигездә ите мөселманнарга куллану тыелган терлек майларыннан ясала. Хәләл желатин да бар. Кайбер җитештерүчеләр аны балык сөякләреннән, үсемлекләрдән ясыйлар. Иншә Аллаһ, киләсе елга бездә дә хәләл желатин җитештерә башлаячаклар, аны азык-төлеккә дә, фармацевтикада да файдаланып була.

**А.Ә.:** - Составында спирт булган даруларны кулланырга ярыймы?

**И.Б.:** - Белгәнебезчә, Аллаһы тәгалә спиртлы эчемлекләрне эчүне тыйды. Әгәр инде составында спирт булган дару эчәргә кушканнар икән, кеше аны алмаштыра торганын эзләргә тиеш.

**А.Ә.:** - Хәзер сатуда хәләл пепси, кола гына түгел, шәраб, сыра да бар. Монысына ни әйтерсез?

**М.Н.:** - Без әлегә хәләл пепси, коланы сертификацияләмәдек. Ә "хәләл шәраб" сүзтезмәсен куллану бөтенләй дә урынсыз, чөнки шәраб баштан ук тыелган эчемлек. Без моңа тискәре карыйбыз. Бу эчемлекләрне шәраб, виски дип атавыбыз ук, аларны эчсәк, безне шушы эчемлекләрнең исерткеч аналогларын эчүчеләргә тиңләштерәчәк.

**И.Б.:** - Хәләл шәраб турында укыгач, мин аны нәрсәдән ясыйлар икән дип кызыксындым. Гадәти шәрабның спиртын чыгару юлы белән ясыйлар икән, башкача әйткәндә, бу эчемлек баштан ук хәрам булган.

**А.Ә.:** - Куас дигән рус эчемлегенә килсәк…

**И.Б.:** - Төрле җитештерүчеләрнең куасларын карасак, шуны күрергә була - кайберләренең составында спирт бар, ә кайберләре спирт катыштырмый. Составында спирт булган куасны куллану тыела. Ә менә спирт әчегәндә барлыкка килсә, һәм аның күләме зур булмаса, мондый куасны эчәргә ярый.

**М.Н.:** - Чөнки куасның состав өлешләре хәләл. Күп булмаган күләмдә алкоголь кефирда, кумыста, икмәктә дә бар.

**А.Ә.:** - Хәләл продукция сатып алганда нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

**М.Н.:** Беренче чиратта ризыкның тышкы кыяфәтенә, кабына игътибар итәргә, составы белән танышырга һәм җитештерүнең кем тарафыннан контрольлек ителүен карарга кирәк. Составында тыелган, шикле компонентлар күрсәгез, андый азык-төлекне алмавыгыз хәерле. "Мусульманская", "татарская" дигән язуларга килгәндә, болар -аерым бер категория сатып алучыларны җәлеп итү өчен уйлап табылган маркетинг алымы гына. Без үзебезнең комитет тарафыннан сертификацияләнгән товарны гына алырга киңәш итәбез, чөнки "Халяль" Россиядә беренче булып теркәлде, алар барлыгы алты гына. Продуктны сертификацияләүдә ике оешма - безнең комитет һәм "Тест-Татарстан" (стандартизация, метрология һәм сынаулар уздыру буенча дәүләт төбәк үзәге) катнаша. Без шәригать күзлегеннән хәләллеген тикшерсәк, "Тест-Татарстан" аның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын карый. Шулай ук ризыкның ничек сатылуына да игътибар итәргә кирәк. Кайчан хәләл ризык хәләл булмаганы белән бергә сатыла, бергә саклана, моңа юл куелырга тиеш түгел.

**А.Ә.:** - "Хәләл" сертификатын ничек алырга була?

**М.Н.:** - Бүгенге көндә безнең шаһадәтнамәне алган 80 нән артык предприятие бар. Шаһадәтнамәне - без, ә хәләлгә туры килү сертификатын "Тест-Татарстан" бирә. Бу таныклыкларны алу өчен комитетка хат-гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Гаризаны караганнан соң без, урынга барып, чималдан башлап бөтен җитештерү циклын өйрәнәбез. Ит ризыкларына таләпләр бик катгый - һәр кошчылык фабрикасына контролерларыбыз беркетелгән.

***"АЗАН" интернет-радиосында Алмаз ӘХМӘТҖАНОВ үткәргән әңгәмәдән кыскартып алынды***

http://radioazan.ru

## КАЗАНДА ИКЕНЧЕ "ХӘЛӘЛ" РЕСПУБЛИКА ЯРМИНКӘСЕ ҮТӘЧӘК

***29 ноябрьдә "Казан" агросәнәгать паркында икенче республика "Хәләл" азык-төлек ярминкәсе үтәчәк. Ярминкәдә 60 ка якын җитештерүченең хәләл продукциясе: ит һәм сөт, кондитер һәм башка төр ризыклар сатылачак.***

Ярминкә кысаларында төрле мәдәни чаралар, конкурслар һәм "Ярдәм" реабилитация үзәгендә тәрбияләнүчеләрнең кул эшләреннән күргәзмә оештыру да каралган.

Ярминкәне ТР МДН каршындагы "Хәләл" стандарт комитеты һәм ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы оештыра.

Ярминкә сәг. 8.00-15.00 кадәр Казан шәһәре, Аграр урамы, 2 йорт ("А"залы) адресы буенча булачак.



# СТУДЕНТЛАРЫ ТӨШЕРГӘН СЕРИАЛ РЕКТОР КҮҢЕЛЕНӘ ХУШ КИЛДЕ

***Россия ислам институтында ел да мөселман мәдәнияте һәм киносы фестивале уздырыла. Аның быелгысы "Мөселман уку йортларының уку-укыту эшчәнлегендә инновацион технологияләр" дигән халыкара фәнни-гамәли конференция кысаларында барды. Фестивальне институт студентлары конференция кунаклары өчен сәубуллашу бүләге итеп әзерләгән иде.***





Фестиваль үз эшен берничә номинациядә алып барды. РИИның төрле факультетлары студентлары аудиторияләрен үзләре тәкъдим иткән илләр һәм милләтләр стилендә бизәделәр, милли ризыкларны әзерләүдәге осталыкларын да күрсәттеләр. Студентлар үзләрен сәхнәдә дә сынап карады. Алар жюри хөкеменә төрле темаларга импровизацияләрен тәкъдим итеп, актерлык осталыкларын күрсәттеләр.

Институт тормышындагы бу мөһим чараның "төше" - РИИ студентлары үзләре төшергән "Знаковые судьбы" сериалын тәкъдим итү булгандыр, мөгаен. Күктән йолдыз чүпләмәсәләр дә, беренче беленнәре төрле чыкмады яшьләрнең.

Мәртәбәле жюриның рәисе итеп "Татаркино" директоры урынбасары Рәис Садриев чакырылган иде. Аның белән бергә студентларның эшләрен "Татаркино"ның бүлек начальнигы Ирина Ульянова һәм Пятигорск дәүләт лингвистика университетының көнчыгыш телләре һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире Ибраһим Ибраһимов бәяләде. Шулай итеп, "Милли кием һәм кабинетны бизәү" номинациясендә лингвистика командасы җиңде, икътисадчыларның стена газетасы иң яхшысы дип табылды, ә кулинария сәнгатендә "Тәхфиз" командасына тиңнәр булмады. "Ректорның махсус призы"н Рәфыйк Мөхәммәтшин "Знаковые судьбы" сериалын төшерүче төркемгә тапшырды.

***Islam-Today***

# ЕГЕТЛӘР ХАЖГА ВЕЛОСИПЕДТА БАРЫРГА ҖЫЕНА

**Ни өчен алар нәкъ менә велосипедны сайланган, төрле илләр аша сәяхәт итү куркытмыймы, ниятләре ныкмы? Ике тәгәрмәчле транспортка утырып, хаҗга чыгып китәргә тәвәккәлләгән төркемнең җитәкчесе Булат Насыйбуллин әлеге сорауларыбызга бик теләп җавап бирде.**

Булат - Әлмәт егете. Бүгенге көндә Г.Плеханов исемендәге Россия икътисад университетының V курсында укый. Шул ук вакытта Казанның Кабан арты мәчетендә мөәзин булып тора. Унбиш яшьләрендә күңеленә кереп оялаган изге теләге, аны еллар буе озата килгән. Үсмер егет ул чагында фикердәшләр тапмый. Шулай да хыялны чынга ашыру теләге елдан-ел көчәя генә бара. Соңрак Булат үзе кебек уйлаучы иптәшләрен очрата. "Нәкъ менә вакыт сарыф итеп, хаҗ кылуның бөтен тәмен белеп Аллаһыга метрлап-метрлап якынаерга телибез", - ди ул.

Бер карасаң, 22 яшь - әле гомернең башы гына шикелле, әмма төптәнрәк фикер йөртсәң, адәм баласы тормышында ул иң кирәк вакыт, югарырак этапка күчә торган вакыт. Нәкъ шушы этапка Булатның һәм аның фикердәш дусларының чистарынып керәсе килә. Башта алар бөтен маршрутларын ачыклап, картасын, планнарын әзерләп, Кабан арты мәчете имам-хатыйбы Сәеджәгъфәр хәзрәткә күрсәткәннәр. Аның фатихасын алганнан соң, Татарстан мөфтие янына килгәннәр. Әлеге идея Камил хәзрәт Сәмигуллин тарафыннан да яклау тапкан, көченнән килгәнчә ярдәм итәргә ышандырган.



Хәзерге вакытта егетләр сәфәр юлларын планлаштыралар. Сугыш кагылмаган илләр аша барырга исәплиләр. Маршрут әзерләнеп беткәннән соң, Диния нәзарәтенә тапшырачаклар. Нәзарәт хуплый икән, ул вакытта инде әзерлек тулысынча, бар көченә башланачак. Төрле илләр чиген узганда, виза кыенлыклары килеп чыкмас, дип өметләнә яшьләр.

- Булат, кайбер мәгълүмат чараларында, хаҗ кылу кыйммәтләндә, яшьләр шуңа күрә велосипедта барырга мәҗбүр, дигән кебегрәк мәгълүмат таралды. Велосипедта мөкатдәс сәфәрне башкару, киресенчә, кыйммәткәрәк төшә торгандыр ул.

- Әлбәттә шулай. 80 шәр чакрым үтсәк (ике тапкыр ял итеп), без 88 көн юлда булачакбыз дигән сүз. Шуны аңласыннар иде: монда финанс ягы мөһим түгел. Максатыбыз - бабаларыбыз кебек хаҗ кылу. Алар хаҗга җәяү дә, атта да барганнар. Ә велосипед бу ике төрне берләштерә: физик яктан да хәрәкәтләнәсең, шул ук вакытта атка атланган сыман утырып та барасың.

Төркемдә Шамил исемле тагын бер татар егете бар. Заманында аның бабасы Россия мөселманнарын изге җирләргә җәяүләп алып барган дин эшлеклесе булган. Шамил өчен бу изге гамәл, үзенә күрә символик мәгънәгә дә ия икән әле.

Егетләр сәфәр вакытында юл вакыйгаларын бәян иткән фильм эшләргә дә ниятләп торалар. Төркемдә режиссер-оператор да булачак. "Аллаһыга якынаю юлы" дигән фильмның сценариен әзерли дә башлаганнар инде. "Башкаларга, мөселманнар Аллаһ юлында берләшсәләр, теләсә нинди авырлыкларны да җиңеп чыгачаклар, дигәнне күрсәтәсебез килә", - ди Булат.

Сүз дә юк, Хаҗ кылу рухи әзерлек таләп итә, ә менә велосипедта 5000 чакрымнан ераграк юлга ниялләп чыгу өчен сәламәтлек тә кирәк бит әле. "Без, әлбәттә, физик яктан әзерләнәчәкбез, - ди егетләр. - Әмма монда иң мөһиме - рухи әзерлек. Әгәр дә ниятләребез изге, дөрес икән, Аллаһы Тәгалә безгә бу эшне башкарып чыгарга насыйп итәр!"

2015 елның 25 июнендә егетләр Болгардан кузгалырга ниятлиләр. 10 сентябрьгә билгеләнгән урынга барып җитәчәкләр. Егетләрнең маршрутлары Әзербайҗан, Иран, Кувәйт аша үтәчәк. Интернет челтәрендә махсус сайт ачып, шунда алар юлъязмаларын урнаштырып барырга җыеналар.

***Мәршидә КЫЯМОВА,***
***intertat.ru***

# Россия мөселман яшьләре берлегенең Төмәндә филиалы ачылды

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Төмәнгә эшлекле сәфәре кысаларында мөселман яшьләре белән аралашты. Очрашу вакытында төбәк яшьләре үзләрендә Россия мөселман яшьләре берлеге вәкиллеген булдыру теләген җиткерделәр.**

Әлеге берлек җитәкчесе Марсель Сабиров сүзләренә караганда, Төмән бүлеген җитәкләргә Зөфәр Мөхәммәтшин сайланган. "Берлекнең максаты Россия күләмендә актив мөселман яшьләрен туплаудан гыйбарәт. Без яшь буынны традицион ислам кыйммәтләрендә тәрбияләү ягында. Шулай ук Татарстан һәм башка төбәк мөселманнары арасында үзара хезмәттәшлек итүне үстерергә телибез. Яшьләр арасында сәламәт яшәү кануннарын пропагандалыйбыз, ислам кыйммәтләре нигезендә тормыш алып барырга чакырабыз. Берлек филиалы барлыкка килү Төмән төбәге мөселман яшьләренә үсәргә, максатларын тормышка ашырырга күбрәк мөмкинлекләр бирер дип ышаным", - диде Марсель Сабиров.

*Хатларыгызны Диния нәзарәтенә(Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз*

# МИНЕ ИСЛАМГА ИЛТКӘН ЮЛ

*Мәрьям белән без татар теле курсларында таныштык. Элек чиркәүгә йөргән рус кызы моннан берничә ел элек ислам динен кабул иткән икән. Үзе турында ул миңа ниләр сөйләде.*

*"Шәригать кушканча яшәү - бик аңлаешлы, җиңел тормыш, дип саныйм мин. Исламда хатын-кыз бик хөрмәтле, аның хокуклары якланган, Аллаһы тәгалә каршында да әҗерсаваплары күп. Мин әле күптән түгел генә, гап-гади нәрсәләрне дә аңламыйча, башкалар кебек яши һәм уйлый идем. Бар да үземнән, үз тырышлыгымнан, алдыма куелган хыялларымнан тора, янәсе. Бөтен дөньяви максатларга да ирешелгән: ир, бакча, машина. Әмма Илаһи Зат, мин белмәгән, бары тик барлыгын тоемлаган гына тормыш турындагы уйлар миңа беркайчан да тынгылык бирмәде. Шуңа да һәрвакытта эзләнүдә идем. Рус милләтеннән булганлыктан, әнием мине сабый чагымда ук чукындырган, шуңа күрә чиркәүдә җаныма - тынычлык, сорауларыма җавап табармын, дип уйладым. Кызганычка, бәлки, бәхеткәдер, сораулар тагы да артты һәм ешайды гына.*

*Аллаһы шулай кушкандыр инде, ирем дә дин белән кызыксынып китте. Ул татар кешесе, хакыйкатьне исламнан эзли башлады. Алган гыйлемнәрен минем белән дә бүлешә, киңәшә иде. Бервакыт кинәт кенә айнып киткәндәй булдым, ничә еллар буе мине дулкынландырган, борчыган сораулар исламда җаваплар бар икән бит. Әлхәмдулилләһи, иремә бик рәхмәтлемен. Ул мине йомшаклык белән, мәҗбүриләмичә ислам диненә алып килде. Тугыз ел буе балабыз булмаган иде, 5 вакыт намазга баскач, Аллаһы тәгалә безгә биш ел эчендә 3 бала бүләк итте. Хаҗга бару һәм гыйлем алу мөмкинлеге бирде.*

*Аллаһының берлегенә ышанмый торып, кеше күңеленә тынычлык таба алмый. Һәркайсыгызга озын-озакка сузмыйча, югалтуларсыз гына шушы дәрәҗәләргә ирешергә насыйп итсен".*

**Элдар МИРЗАГАЛЛӘМОВ**

# ТҮБӘТӘЙ КИГӘН МАЛАЙ

Түбәтәй кигән бер малай,
Моңлы азанны ишеткәч,
Намазга соңарам, диеп
Көн дә йөгерә мәчеткә.

Ә кичләрен шушы малай
Коръәнен ала кулына,
Шул чак әллә нәрсә була -
Бөтен дөньясы тын кала.

Әти, әни, әби, бабай...
Тын да алмый аны тыңлый;
Нәни, әмма нык иманлы
Түбәтәй кигән бу малай.

# ЙӨРӘГЕҢДӘ АЛЛАҺ БУЛСЫН...

Саф хисләр, изге ниятләр
Туып тора күңелдә,
Аллаһка мәхәббәт булгач,
Йөрәгеңнең түрендә.

Изге юлларда йөрергә
Язсын безгә бүген дә,
Хәләл ризык кына булсын
Табыныбыз түрендә.

Авырлыклар артта калсын -
Аллаһтан шуны сорыйк.
"Ныклы иман, бәхет-тәүфикъ
бир", - диеп дога кылыйк.

**Ленур ИКСАНОВ**

# ЯШЬЛӘР КӨНЕН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕК

Диннәренә, милләтләренә, сәяси карашларына карамыйча, бөтен дөнья яшьләрен изге гамәлләрдә берләштерә торган бер көн бар - Бөтендөнья яшьләр көне дип атала ул. Бу көнне Татарстан яшьләре дә билгеләп үтә. Бәйрәм чарасының быелгысы Казанда Муса Җәлил музеенда узды. Һәм бу очраклы гына түгел. Яшьлегендә Муса Җәлил дә шат күңелле, җырга-моңга оста әйдәп баручы студент һәм бик шәп шагыйрь булган. Безнең кичә дә талантлы яшь шагыйрь Булат Ибраһимов белән аралышып узды. Шигырьләр яңгырады, сөйләшү сәнгать, иҗат турында барды. Булат күптән түгел генә "Балык теле" исемле шигырьләр җыентыгы бастырып чыгарган икән. Китап чыгару авыр һәм җаваплы, әмма шатлыклы вакыйга. Шул уңайдан ул яшьләргә иҗаты, җыентык чыгару өстендә ничек эшләве, яраткан шагыйре Һади Такташ шигъриятенә мөнәсәбәте турында сөйләде. Муса Җәлил иҗатына тукталып: "Шигырьләрен укыганда ул чын патриот, сынмас рухлы, горур кеше булып күз алдына килеп баса", - диде.

Кичәнең тагын бер кунагы - биюче, җырчы, нәфис сүз остасы, шуның өстенә Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты Гөлнара Хәйруллина булды. Гөлнара 3 яшеннән бирле сәхнәдә икән, җырларыннан диск чыгарган, бию студиясен тәмамлаган, югары уку йортында актерлык һөнәрен үзләштергән, "Татар кызы" исемен яулаган кыз. "Һәр кеше сәләтле, бары тик эзләнергә, тырышырга гына кирәк", - дип яшьләр күңеленә өмет салды ул. Аннары Муса Җәлилнең иң яраткан шигырьләрен укып күрсәтте, җырлар башкарды.

Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев үзенең чыгышын матур һәм моңлы җыр белән башлап җибәрде:

***Сорыйм синнән миңа,***
***Раббым,***
***Шул дүрт нәрсәне насыйп ит:***
***Бере - гыйлем, бере - гамәл,***
***Бере - саулык, бере иман.***

Җырдагы: "Раббым, исән чакта җирдә изгелек кылырга мөмкинлек бир", - дигән сүзләр Миңгол абыйның томыш девизына ук әверелгән инде. Татар халкы бөтен дөнья буйлап сибелгән һәм бөтен яктан үрнәк булып яши, дип саный ул. Миңгол абыйның үзен эзләп, анда укырга дип Россиянең һәм дөньяның төрле почмакларыннан киләләр. "Сәнгать, моң аша кешеләрнең күңелен җылытасым килә", - ди халкыбызның яраткан җырчысы.

**Илсөяр ГАБИТОВА**

# ӘЛМӘТТӘН БАЕП КАЙТТЫК

*Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев мөгаллимнәргә Әлмәт ягына сәяхәт кылырга тәкъдим ясагач, бик теләп ризалаштым. Без туп-туры күренекле мәгърифәтче-галим Ризаэддин Фәхретдиннең мирасын өйрәнүгә һәм аны белем һәм тәрбия бирү процессында куллануга багышланган чарага - галимнең туган авылы Кичүчатка юл алдык. Ризаэддин хәзрәт хезмәтләреннән дәресләрдә даими файдалансак та, аның туган авылын, ул яшәгән нигезне беребезнең дә күргәне юк иде.*

*Мәктәпнең мәһабәт бинасы чиста-пөхтә ишегалляры белән ерактан балкып, үзенә дәшеп тора. Ишекләрне ачып керүгә милли киемдәге ягымлы йөзле малайлар, кызлар каршы алды. Кулларында пешерү серен бары әлмәтлеләр генә белгән татлы бавырсак. Балаларның күңелләрне айкарлык матур чыгышларыннан соң түргә узып, мәктәп белән танышабыз. Бай як шул, җиһазланышы, бизәлеше зәвыклы.*

*Очрашуга Әлмәт районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов, авыл имамы, мәгариф бүлеге хезмәткәрләре, районның тел, әдәбият, әхлак мөгаллимнәре дә килгән иде. Мәктәп белән танышкач, 6 нчы сыйныфка ачык дәрескә кердек. Диварга галим портретын һәм: "Кешенең иң олы байлыгы акыл, гыйлем һәм әдәплелек",- дигән канатлы гыйбарәне язып элгәннәр. Китаплар күргәзмәсендә Ризаэддин мулланың әле без күрмәгән китаплары белән танышу бәхетенә дә ирештек. Тел-әдәбият укытучысы Рәсимә Минсәгыйрь кызының дәресеннән үзебез өчен кызыклы мәгълүматлар алу белән генә чикләнмичә, укыту-тәрбия процессында кулланылган яңа технологияләр белән дә таныштык. Сөйләшү түгәрәк өстәл артында дәвам итте. Мәктәпләрдә әхлак дәресләре укытуның чишмә башында торган Бөрбаш мәктәбе директоры Гүзәл Бариеваның осталык дәресе күрсәтүе очрашуга ямь өстәде.*

*Бу төбәкнең үзгә нигъмәтләре белән сыйлангач, Ризаэддин Фәхретдиннең музеййортына юнәлдек. Каршыбызда гап-гади борынгы авыл өе. Туган нигезләрне искә төшереп, күңелләрне сагыш сара. Тын гына әчкә узабыз. Сөбханалла! Каршымда республикада даими үткәрелүче Ризаэддин Фәхретдин укуларында танышкан филология фәннәре кандидаты Диләрә Гыйматранова басып тора!*

*Музей эшчәнлеге минем өчен аеруча кызыклы. Карадуган мәктәбенә кайтып эшли башлагач, 1976 елда мәктәптә Муса Җәлил музее төзеп, аны ун ел буе җитәкләгән идем. Ә Кичүчатта музей 1995 елда ачылган. Һәм тирә-якның гына түгел, бөтен районның әхлак тәрбиясе үзәгенә әверелгән. Музей эшчәнлеген җәелдерү өчен бер генә мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмаска тырыша мондагы хезмәткәрләр. Әллә ничә төрле грант кына отканнар. Иганәчеләр дә нык ярдәм итә икән. Залларга 300 дән артык экспонат куелган булса, фондта 4 меңнән күбрәк эшкәртәсе, өйрәнәсе хәзинә тупланган. Безне иң гаҗәпләндергәне - Ризаэддин мулланың нәсел шәҗәрәсен яктырткан зал уртасындагы агач булды.*

*Ризаэддин Фәхретдиннең мирасын танытуда күп эшлиләр әлмәтлеләр. Хәтта Мәскәүдә, Кызыл мәйданда мәскәүлеләрне, килгән кунакларны хәзрәтнең хезмәтләре белән таныштырып, бер атна басып торган Диләрә Габделкави кызы. "Янымнан кеше өзелмәде, русчага тәрҗемә ителгән китапларын сорап аптыраттылар", - дип сөйләде ул.*

*Әлмәтнең Ризаэддин Фәхретдин исемендәге җамигъ мәчете безне кабатланмас архитектурасы, зурлыгы белән таң калдырды. Бу гаҗәп бинада икенде намазын укып мәдрәсәгә барып, анда кызлар һәм ир балалар мәдрәсәләрендәге уку, яшәү шартлары белән таныштык...*

*Бер кочак тәэсирләр, кыйммәтле мәгълүматлар, белем һәм күчтәнәчләр тияп кайттык без бу сәфәрдән. Аны оештырган Җәлил хәзрәткә, район хакимияте җитәкчесе Рамил Нотфуллинга, мәгариф бүлеге башлыгы Алия Юныс кызына һәм, әлбәттә, әлмәтлеләргә барлык мөгаллимнәр исеменнән рәхмәтебезне җиткерәм.*

**Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА, Балтач районы, Шубан мәктәбенең әхлак мөгаллимәсе**

# ЮЛДАН ЯЗГАННАРНЫҢ КУРКЫНЫЧ ФИКЕРЛӘРЕ

**Имам әш-Шәһрестани (һиҗри белән 479-548 нче еллар / милади белән 1087-1154 нче еллар) болай дигән: "Шуны бел: күп сәләфләр Аллаһы тәгаләне гыйлем, кодрәт, тормыш, ихтыяр, ишетү, күрү һәм сөйләм сәләтләре, рәхимлелек, куәт кебек, баштан ук бакый сыйфатлар белән тасвир иткән.**

Ләкин аның асыл һәм гамәл сыйфатларын аермаганнар. Алар Аллаһыны, шулай ук, "әл-йәдәйн", "йәд", "гәйн" кебек хәбәрия сыйфатлары белән дә тасвир иткән, ләкин аларның аллегорик мәгънәгә ия икәнлеген аңлатмаган. Бу сыйфатлар турында сөйләгәндә алар: "Болар - хәбәрия сыйфатлары", - дигән". (Хәбәрия сыйфатлары - аларның булуын аң белән аңлап булмый, аны бары Коръән һәм Сөннәт аша гына аңлап була. Мәсәлән, "йәд" сыйфаты - сүзгә-сүз тәрҗемәдә "кул" дигәнне аңлата, ә "үәҗһ" сыйфаты - "йөз" дигәнне. Шуңа күрә дә аларны, туры мәгънәсендә, сүзгә-сүз аңлау дөреслеккә туры килми. Әгәр дә шул рәвешчә аңлатсак, без Аллаһы тәгаләнең тән өлешләре бар дип күрсәтәбез).

Мөгътәзилиләр сыйфатларны инкяр иткән, ә сәләфләр аларның барлыгын дәлилләгән. Сәләфләрне - сыйфатчылар дигәннәр, ә мөгътәзилиләрне - могаттыйльләр. Кайбер сәләфләр Аллаһыны тасвир иткәндә тәшбиһ чиген узып киткән, алар Аллаһы тәгаләне башлангычы булган сыйфатлар белән тасвир иткән. Аларның кайберләре Аның гамәлләре күрсәткән сыйфатлар белән чикләнгән. Хәбәрия сыйфатлары буенча сәләфләр ике төркемгә бүленгән.

Кайбер сәләфләр бу сыйфатларны аллегорик аңлатканда, ул сүзләр киң кулланылышта нәрсә аңлатса, сыйфатларга да шул ук мәгънәне салып аңлаткан. Кайбер шәрехләүчеләр тәэуилдән баш тарткан: "Без шуңа инанганбыз: Аллаһыга охшаш берни дә юк, Аллаһы тәгалә яратылганнарның берсенә дә охшамаган, бер генә яратылган зат та Аллаһыга охшамаган. Без моңа инанганбыз һәм: "Ул - Аллаһы Гарешкә истива кылды", - аятендә (Коръәннең кайбер тәфсирләрендә: "Аллаһы Гареш өстенә утырды", - дип шәрехләгәннәре дә бар) килгән ул сүзнең ("истива" сүзенең) нәкъ менә нәрсә аңлатуын без белмибез һ. б." - дигәннәр.

Алар, янә: "Без бу аятьләрнең тәфсирләрен белергә тиеш түгелбез, ләкин, Аңа тиңдәшкә илаһ китермичә, Аңа охшаш башка берни дә булмавына инанып, без аларны ничек бар шулай кабул итәргә тиешбез", - дигән.

Шуннан соңгы чорның кайбер галимнәре: "Аларны туры мәгънәсендә аңларга кирәк", - дип әйткән һәм шуның белән тәшбиһкә батканнар, шул рәвешчә сәләфләргә каршы килгәннәр. Тәшбиһ барысы өчен булмаса да, бу - яһүдиләргә хас күренеш булган. Анныры - бу чиктән чыккан шигыйларга да хас сыйфат булган. Алар үзләренең кайбер имамнарын илаһилаштыра башлаган. Сәләфләр арасында мөгътәзилиләр һәм мөтәкәллимнәр килеп чыккач, кайбер рафидыйлар, үзләренең чик позицияләрен ташлап, мөгътәзиләчелеккә күчкән. Ә кайбер сәләфләр туры мәгънәсендә, сүзгә-сүз аңлау нәтиҗәсендә, тәшбиһкә баткан.

Тәэуил эшләмәгән, тәшбиһкә дә якынлашмаган сәләфләргә килгәндә исә, алардан Малик ибне Әнәсне (Аллаһы аңардан разый булса иде!) күрсәтергә була. Ул болай дигән: "Истива - мәгълүм, ничеклеге - тәҗһүл, ә аның турында сорашу - бидгать". Суфьян әс-Сәүри, Дауд ибне Гали әл-Әсфәһани һәм аңа тәкълид иткән башка галимнәр дә бу мәсьәләгә шундый ук караштa булган" [әш-Шәһрестаниның сүзләре тәмам].

Ул тагын түбәндәгеләрне әйткән: "Кайбер чиктән тыш шигыйлар һәм әсхәбел-хәдис (хәшәвиләр) Аллаһыны ул яратканнарга ачыктан-ачык тиңләштергән. Алар үзләренең табыну объектының "кыяфәте, аерым бер өлешләре, әгъзалары бар, Ул бер урыннан икенче урынга күчәргә, утырып торырга, матди расланырга сәләтле; аларның Раббысы үзе яраткан затка физик яктан кагылып, тиеп карарга сәләтле" диләр. Шуңа игътибар итегез: мүҗәссим мәзһәбенә барысыннан да ныграк Ибне Тәймия чакырган. Аның китаплары шундый әйберләр белән тулы. Ул: "Аллаһының физик әгъзалары бар, ул Үзе яраткан затка физик яктан кагылып карарга мөмкин, ул бер урыннан икенче урынга күчә ала, Гарештә утыра", - дип раслый. Ибне Тәймия буенча, Аллаһы - тәнгә, гәүдәгә ия, Ул пространствода бар яклардан да, бар юнәлешләрдә дә чикләнгән (Кара: "Әл-Кәшф әс-Сагир")".

Дауд әл-Җәвәрибидән (мүҗәссим) тапшыралар: "Без: "Аллаһының, сакал һәм җенси әгъзалардан тыш, калган барысы да бар", - дип әйтәбез". Аларның кайберләре: "Аллаһы, ул - аерым бер өлешләрдән, әгъзалардан, ит һәм каннан торган тән, ләкин, башка тәннәр кебек тән түгел, аның ите һәм сөякләре - башка төрле, Ул яраткан затларның итләре, сөякләре кебек түгел", - дигән.

Имам әш-Шәһрестани аннан килеп болай дигән: ""Истива", "үәҗһ" һәм, Коръәндә булган, шуңа охшаш башка сүзләргә килгәндә, алар бу сүзләрне туры мәгънәсендә, сүзгә-сүз аңлаган, ягъни аларны тәннең бер өлеше мәгънәсендә кулланылганча кабул иткән. Ә бу исә - Әһлес-сөннәттә "сүзгә-сүз" мәгънәсе салынган әйбер үзе инде, ягъни җисемнәрнең реальлегенә кагыла торган төшенчә. Без, барыбыз да, тәннән һәм җаннан торабыз, бу дөньяда тән аспекты җан аспектыннан өстенрәк йөри. Тәннең өч үлчәме бар. Әшгариләр, шулай ук, бер үлчәмгә ия булган әйберләрне дә тән дип атаган. Ә без барысы да кабул иткәннәргә таянып эш итәрбез. Бу дөньяда без кулланган сүзләрнең күбесе матди, җисми мәгънәгә ия. Сүзне кулланганда уйга иң беренче аның җисмилеге белән бәйле мәгънәсе килә, чөнки ул тирә-яктагы чынбарлык белән ныграк бәйле. Бу безгә - кешеләргә - мөнәсәбәттә шулай.

Ләкин без, Аллаһыга карата мөнәсәбәттәге әйберләрне караганда, Аның кодрәте һәм бөеклеге турында сөйләргә теләгәндә, аның өчен нинди сүзләр кулланырга тиеш соң? Үзебез һәрвакыт кулланган сүзләрне түгелмени? Коръән гарәп телендә иңдерелмәгәнмени? Ләкин без шуны аңларга тиеш: сүзләрнең кешеләрнең табигатенә карата кулланылган мәгънәләрен Раббыбызга карата да куллануны аңыбызда күз алдына да китерергә мөмкин түгел. Сүз аннан килеп чыккан әйбер мәгънәсендә дә кулланылырга мөмкин, аннан тыш, күчермә мәгънәдә дә. Кайбер сүзләрне аңлатканда Әһлес-сөннәттә шул юлны алдылар да инде, бу - тәэуил дип атала. Бу ысулның асылы шунда: сүзне үзебезгә карата кулланганда без аңлаган мәгънәсе аны Аллаһыга карата кулланылгандагы мәгънәсеннән аерыла. Әгәр без бу вакытта аларның мәгънәләре бер үк дип исәпләсәк, без мөшәбиһ булабыз. Бу - тел, логика, шәригать кагыйдәләренә туры килә, бер генә акыллы кеше дә моңа каршы килә алмый. Мүҗәссимгә килгәндә исә, алар сүзләрнең үзебезгә карата кулланган мәгънәләрен Аллаһыга карата да куллана башлаган, нәкъ менә шуның аркасында алар тәҗсим һәм тәшбиһкә баткан. Имам әш-Шәһрестани бу моментны җентекләп аңлата: сүзләрнең иң беренче уйга килә торган "туры" мәгънәсен (ә бу аның җисми мәгънәсе) без аны Аллаһыга карата кулланганда инкяр итәргә тиешбез.

***Сәид Фуданың "Анализ современного состояния шариатского знания" китабыннан (Мәскәү, 2012)***

# "Бөтен дөньяны юктан бар иткән Аллаһның булуына дәлилләр бармы?"

**"Бөтен дөньяны юктан бар иткән Аллаһның булуына дәлилләр бармы?" дип сораучыларга без түбәндәгечә җавап бирәбез: "Аның иҗат җимешләре булуы ул - үзе үк аларны иҗат иткән Останың булуына дәлил". Материалистлар, натуралистлар, дәһриләр тере организм барлыкка килгән эмбрионның башлангыч ноктасы юк, шулай ук үсемлек тишелеп чыга торган орлыкның да башлангыч ноктасы юк дигән версияне (аңлатмаларның берсен - Ред.) алга сөрә.**

Алар фикеренчә, бар бу дөнья дүрт элементтан (барлык әйберләрнең һәм табигать күренешләренең нигезендә ята торган кисәкләрдән - Ред.): утның эсселегеннән, һаваның суыклыгыннан, җирнең корылыгыннан һәм суның сыек матдә булуыннан барлыкка килгән.

Шулай дип әйтүчеләргә без болай дибез: "Барыбыз да Гарәбстан кебек эссе якларда үсемлекләрнең, агачларның, болыннарның - кышын яшәрүен, ә җәен - кибеп, корып көюләрен күрәбез, ә фасоль кебек башка кузаклылар анда җәен дә корымый һәм кипми. Әгәр алар барысы да шул дүрт элемент тәэсирендә барлыкка килгән табигать җимешләре булса, бу үсемлекләрнең әлеге очракта "үз-үзләрен тотышы" бер үк төрле булган булыр иде. Ягъни, алар бер үк шартларда, бер үк вакытта барлыкка килеп, бер үк формада булыр һәм бер үк закончалыклар буенча үсәр һәм яшәр иде. Ләкин, бу - алай түгел. Бер үк шартларда төрле үсемлекләр төрле формада, төрле закончалыклар буенча үсә, үз-үзләрен төрлечә тота. Аллаһ яралтканнарның бер үк шартларда төрле сыйфатларга ия булуына игътибар иткәндә, аларда Кодрәтле Иҗатчыбыз барлыкка китергән процессның барлыгын күрергә мөмкин. Без, шулай ук, бер үк җирдә, бер-берсе янында гына үскән агачлардагы җимешләрнең исе, тәме, төсе аерылып торуын да күрә алабыз. Ә бит материалистлар әйткән ул ут, һава, җир һәм суның тәэсире бер булган бу җирдәге ул агачларның һәр күзәнәгенә дә бер үк төрле. Коръәни-Кәримдә болай диелгән:

**"Аллаһ шулай тәзегән: җимеш бакчалары, игеннәр, икешәрләп вә ялгыз үскән хөрмә агачлары - барчасы бер су белән сугарыла. Тик ашауда тәме белән берсен икенчесеннән артык кылырбыз. Гакылларын эшләткән кешеләр өчен бу нәрсәләрне яралтуда Аллаһның берлегенә, әлбәттә, дәлилләр бар" "*(Рәгыд Күк күкрәү); 13/4)*".**

***Әбу Мүгин ән-Нәсәфинең "Бәхрел-Кәлам" китабыннан (Ул Әһле сөннәт вәл-җәмәгатьнең (матуриди гакыйдәсе) илаһият фәне буенча төп китапларының берсе)***

## МӘСКӘҮДӘ "100К МӨХӘММӘД" ПРОЕКТЫ СТАРТ АЛДЫ

Мәскәүдә "100К Мөхәммәд" дип аталган проект старт алды. Ул "Иң күп авторлар катнашында язылган иң яхшы китап" буларак Гиннеслар Рекорд китабында урын алырга дәгъва кыла. Проект кысаларында 100 мең автор дөньяның иң яхшы кешесе - сөекле Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәлләм турында яза. "Пәйгамбәребез (с.г.в.) турында синең нинди фикерең бар? Бу уникаль проектта катнашырга теләсәң, үз ана телеңдә Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) турында язып җибәр", - дип мөрәҗәгать итә проект авторлары. Шушы проект аша алар Пәйгамбәребезгә мәхәббәт белдерергә, аңа лаеклы гамәл кылырга теләүләрен әйтәләр. Ә без исә үз проектыбызны башлыйбыз.




## ИГЪТИБАР: КОНКУРС!

2 нче гыйнварда билгеләп үтеләчәк Мәүлид бәйрәме - Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең туган көне уңаеннан "Дин вә мәгыйшәт" газетасы Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге белән берлектә үз укучылары арасында сөекле Пәйгамбәребезне (с.г.в.) зурлаган шигъри әсәрләргә бәйге игълан итә. Иҗат җимешләрегезне декабрь ае дәвамында Диния нәзарәтенә (Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru электрон адресына юллый аласыз. Җиңүчеләрне бүләкләр көтә.

## БИШ ЯШЬЛЕК МӨСЕЛМАН MICROSOFTНЫҢ ИҢ ЯШЬ ЭКСПЕРТЫ БУЛДЫ

Бик тә катлаулы имтиханны уңышлы тапшырып, биш яшьлек мөселман малае Аян Куреши Microsoft тарихындагы иң яшь эксперт булды. Чыгышы белән Пакьстаннан булган Куреши хәзерге вакытта Бөекбританиядә яши. Аның әтисе Асим мәгълүмати технологияләр буенча белгеч. Улы турында ул: "Кечкенәдән үк компьютер белән кызыксынды, игътибар белән минем эшләгәнемне карап утыра иде", - дип сөйли. Аннары ул аны компьютер серләренә өйрәтә башлаган.

Аян Microsoft ның бердәнбер яшь эксперты түгел. 2004 елда тугыз яшьлек пакьстанлы кыз Арфа Кәрим дә бу тестны уңышлы тапшырган.



# Салкын пыяланы җылытырлык гөлләр

Татарстанның танылган рәссамы Равил Заһидуллин узган гасырның туксанынчы елларыннан бирле шәмаилләр иҗат итә. "Казан сынлы сәнгать училищесында белем алганда бер дустым миңа гарәп грамматикасы китабын бирде. Шул китап буенча үзлегемнән гарәпчә укырга өйрәндем. Соңыннан мәдрәсәдә уку-язу курсларында белем алдым", - дип сөйли Равил әфәнде иҗатының шундый юнәлеш алуы турында. 1990 елда ул үзенең пыялага майлы буяулар белән язылган беренче әсәрен - "Авыл мәчете белән шәмаил"не иҗат итә. Бу әсәрне "Хәзинә" милли сәнгать галереясының даими күргәзмәсендә күрергә була. Ә башкалабызның 1000 еллыгы уңаеннан игълан ителгән бәйгедә аның югарыда очучы ирекле кошны хәтерләткән Казан шәһәре каллиграфик эмблемасы икенче урынга лаек дип табыла.

"Яңа гына тәмамланган картинам - "Таш мәчет" дип атала. Бу картананы язарга шушы иске мәчетнең матурлыгы илһам бирде", - ди рәссам. Миңа калса, Равил Заһидуллин Казан мәчетләрен киндергә сурәтләүдән кала, аларның интерьерларын да искитәрлек эчтәлектә эшләп чыга алырлык профессиональ рәссам.

Равил Заһидуллинның остаханәсендә Изге Коръән аятьләре язылган шәмаилләре янына пыялага шәмаил язу техникасы алымы белән эшләнгән чәчәкле-бизәкле иҗат әсәрләре дә тезеп куелган, моның белән ул даими төстә инде дүрт ел шөгыльләнә икән. Үсемлек, сабак һәм чәчәкләр бәйләме, катлаулы бизәкләр гармониясенең төгәл ритмы, матур төсләр чишелеше күрсәтелгән бу затлы эшләр, һичшиксез, Татарстанның иң зур музейларына куелырга, иң затлы залларның диварларын бизәргә хаклы.

*Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА*










## Намаз вакытлары Казанда

| Көн | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы | Кыбла |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.12.2014 | 05:31 | 06:18 | 07:48 | 11:32 | 12:00 | 13:27 | 15:16 | 17:11 | 12:36 |
| 02.12.2014 | 05:32 | 06:19 | 07:49 | 11:32 | 12:00 | 13:27 | 15:15 | 17:10 | 12:37 |
| 03.12.2014 | 05:33 | 06:21 | 07:51 | 11:33 | 12:00 | 13:26 | 15:14 | 17:10 | 12:37 |
| 04.12.2014 | 05:35 | 06:23 | 07:53 | 11:33 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:09 | 12:38 |
| 05.12.2014 | 05:36 | 06:24 | 07:54 | 11:34 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:09 | 12:38 |
| 06.12.2014 | 05:37 | 06:26 | 07:56 | 11:34 | 12:00 | 13:24 | 15:12 | 17:08 | 12:39 |
| 07.12.2014 | 05:38 | 06:27 | 07:57 | 11:34 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:08 | 12:39 |
| 08.12.2014 | 05:39 | 06:28 | 07:58 | 11:35 | 12:00 | 13:23 | 15:11 | 17:08 | 12:40 |
| 09.12.2014 | 05:40 | 06:30 | 08:00 | 11:35 | 12:00 | 13:23 | 15:11 | 17:08 | 12:40 |
| 10.12.2014 | 05:41 | 06:31 | 08:01 | 11:36 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:41 |
| 11.12.2014 | 05:42 | 06:32 | 08:02 | 11:36 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:41 |
| 12.12.2014 | 05:43 | 06:33 | 08:03 | 11:37 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:42 |
| 13.12.2014 | 05:44 | 06:34 | 08:04 | 11:37 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:42 |
| 14.12.2014 | 05:45 | 06:35 | 08:05 | 11:38 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:43 |
| 15.12.2014 | 05:46 | 06:36 | 08:06 | 11:38 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:43 |
| 16.12.2014 | 05:46 | 06:37 | 08:07 | 11:39 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:44 |
| 17.12.2014 | 05:47 | 06:38 | 08:08 | 11:39 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 | 12:44 |
| 18.12.2014 | 05:48 | 06:39 | 08:09 | 11:39 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:09 | 12:45 |
| 19.12.2014 | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 11:40 | 12:00 | 13:24 | 15:10 | 17:09 | 12:45 |
| 20.12.2014 | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 11:40 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:09 | 12:46 |
| 21.12.2014 | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 11:41 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:10 | 12:46 |
| 22.12.2014 | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 11:41 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:10 | 12:47 |
| 23.12.2014 | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 11:42 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:11 | 12:47 |
| 24.12.2014 | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 11:42 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:12 | 12:48 |
| 25.12.2014 | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 11:43 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:12 | 12:48 |
| 26.12.2014 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:43 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:13 | 12:49 |
| 27.12.2014 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:44 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:14 | 12:49 |
| 28.12.2014 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:44 | 12:00 | 13:29 | 15:16 | 17:14 | 12:50 |
| 29.12.2014 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 11:45 | 12:00 | 13:30 | 15:17 | 17:15 | 12:50 |
| 30.12.2014 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 11:45 | 12:00 | 13:31 | 15:18 | 17:16 | 12:51 |
| 31.12.2014 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 11:46 | 12:00 | 13:32 | 15:19 | 17:17 | 12:51 |

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
Ноябрь саны, № 11 (232)

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27)* .
**Нәшир: “Хузур” нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН;***
*“Хузур” нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
*Татарстан мөфтие урынбасары* ***Нияз САБИРОВ;***
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ.***

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета “Татмедиа” ААҖ филиалы – “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09617
**Тираж: 5 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **28 нче ноябрь көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес:** naubahar67@list.ru
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**

**Газетада Аллаһы тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллануда сакланыгыз!**